Шәһри КАЗАН

ПӘНҖЕШӘМБЕ, 31 ГЫЙНВАР, 2013 ЕЛ,
N 12 (5190)
WWW.SHAHRIKAZAN.COM

1990 елдан бирле чыга

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

БЕЗГӘ АШЫГЫЧ ЯРДӘМ КИРӘК!

6 бит

2 бит

Бозлавык чоры

9 бит

Максуд ЮЛДАШЕВ:

«Мин эколог булырга тиешле кеше»

КӨН АВАЗЫ

Ятимнәр нәселләреннән артмасын

Күптән түгел Россиядә АКШ гражданнарына бездәге ятим балаларны уллыкка бирүне тыю турында закон чыкты. Хөкүмәттәгеләргә дә үзебезнең гражданнарга уллыкка алу мәшәкатен җиңеләйтү бурычы йөкләнде. Россия Мәгариф һәм фән министрлыгы, әлеге уңайдан, инвалидларны, ун яшьтән олыракларны, бертуганнары булган балаларны үзләренә алган кешеләргә 100 мең сум акча түләргә кирәк, дип белдерә. Бу чаралар белән генә авыру ятим балалар мәсьәләсен хәл итеп булырмы?

Мәдинә МАЛИКОВА, язучы:

– Мин бу йөз мең сум акчаны хәер бирү дип саныйм. Министрлар үзләре күпме акча алып эшли икән? Бу канун керә калган очракта, вазгыять үзгәрер дип тә уйламыйм. Авыру ятим баланы үзенә сыйдыра алучы киң күңелле кеше моңа гына карап тормас. Әмма аларның күңелен күтәрер өчен акчаны бирергә кирәк анысы. Шулай ук америкалыларга бала бирүне тыюга да каршы мин. Безнең үзебездә юкмы бала кыерсытучылар?

Зөһрә СӘХАБИЕВА, Татарстанның халык артисты:

– Ятимнәр элек тә күп булган. Әмма аларны читләргә бирмәгәннәр, нәселләреннән чыгармаганнар. Пәйгамбәребезне дә башта бабасы, аннан абзые тәрбияләгән бит. Ятим балаларның нәсел җебе бер дә булмый калмый. Һич югы берәр туган кешесе тәрбияләсен иде аларны. Ә хөкүмәт ул гаиләләргә ярдәм итсен.

Равил САТТАРОВ, газета укучы:

– Авыру балаларны тәрбияләүче гаиләләргә аларга операция ясату, кирәкле дарулар белән тәэмин итеп тору, кыйммәтле медицина ярдәмен бушка оештыру кебек чаралар да күрелсен иде. Гаиләгә бирелгән 100 мең сум акча белән генә авыру баланың проблемасын хәл итеп бетереп булмый.

«ШК» газетасының 5 февраль — сишәмбе санына алхәбәр

«Сугыштан ул көндәлек белән кайткан. Берничә дәфтәрдән торган бу язмалар еллар үтү белән инде саргайган да. Әмма аларны уку белән, шул сугыш күренешләрен күргән кебек буласың».

Айгөл НУРИСЛАМОВА. «Бабамның сугыш елларындагы кайбер истәлекләре»

Рафис Корбан: «Быел Тукай бәйрәмен дә башкачарак үткәрү нияте бар. Мин студент булганнан бирле катнашам ул опера һәм балет театры бинасы янында узучы бәйрәмдә. Ул миңа ошамый».

Гөлнара ҖӘЛИЛОВА. «Бергә булыйк, аерым торыйк»

Атнага 3 тапкыр чыга торган газетаның индексы – 54126.

«ОШАМАСА, АЕРЫМ ЙОРТ АЛЫГЫЗ!»

5 бит

ПАТШАЛЫК КҮПМЕ ТОРА?

7 бит

ЗАКОННАРЫБЫЗ «ЯМАУГА» МОХТАҖ

10 бит

«Шәһри Казан»да бергә кайныйк! Телефоннарыбыз: (843) 562-50-07 (факс), 562-50-12

РӘСМИ ХӘБӘРЛӘР

Мөфтигә — 50 яшь

РОССИЯ Премьер-министры Дмитрий Медведев ТР Мөселманнары диния нәзарәте җитәкчесе Илдус Фәйзовны 50 яшьлек юбилее белән котлады.

«Татарстан Республикасы Мөселманнары диния нәзарәте җитәкчесе вазифасында хезмәт куюыгыз, кыюлык күрсәтүегез һәм югары дәрәҗәдә гражданлык җаваплылыгы дин вәкилләре арасында гына түгел, ә киң җәмәгатьчелек даирәсендә хөрмәт уята. Сезнең яшь буынга рухи-әхлакый тәрбия бирүгә, конфессияара һәм милләтара диалог үсешенә күп көч һәм вакыт бирүегез әһәмияткә ия», – дигән сүзләр бар РФ Хөкүмәте сайтында дөнья күргән телеграммада.

Казан егете — җиңүче

ТАТАР композиторы Эльмир Низамов «Композитор XXI века» Халыкара заманча музыка бәйгесе лауреаты булды.

Яшь композитор «Ел премьерасы» номинациясендә III дәрәҗәдәге премия иясе. Ул бәйгедә Гомәр Хәйям шигыренә «Без кайдан килдек» вокал циклы белән катнашкан. Моңа кадәр дә «Казан турында риваять» рок-операсы авторы төрле зур шәһәрләрдә үткәрелгән халыкара бәйгеләрдә лауреат булгалаган иде инде. Хәзерге көндә ул Казан консерваториясендә композиция кафедрасы укытучысы булып эшли һәм шунда ук аспирантурада укый.

Утырыгыз да килегез!

МӘСКӘҮ белән Казан арасында туристлык поезды йөри башлый.

Шундый поездның беренчесен Казанда 30 мартта көтәләр. Мәскәү – Казан маршрутында мондый турны әлегә 29-31 март, 1-3 май, 29-31 август көннәрендә оештыру ниятләнә. Туристлык поездының сәфәре җомга кичендә яки бәйрәм көннәрендә Мәскәүнең Казан вокзалыннан башланачак. Туристлар Казанда көндез истәлекле урыннар белән танышканнан соң, кичен кабат Мәскәүгә сәфәргә кузгала. Мәскәү – Казан маршруты буйлап туристлык поездында сәяхәт 7300 сумнан (укучылар өчен) 7900 сумга кадәр (өлкәннәр өчен) тора.

Маршрутлар кыскара

ЮЛЛАРДА төзекләндерү эшләре башкарылу сәбәпле, кайбер шәһәр яны поездларының маршрутлары кыскара.

Коркачык – Арча станцияләре аралыгында юллар төзекләндерелү сәбәпле, 13, 19 һәм 27 февраль көннәрендә 6404/6407 Казан – Арча поезды Бөреле станциясенә кадәр генә йөриячәк. 6923 нче Ижевск – Казан поездының исә Арча – Әмәт участогында хәрәкәт расписаниесе беркадәр үзгәрешләр кичерә. Моннан тыш, 5 февральдә Арча – Курса станцияләре аралыгында алып барылачак төзекләндерү эшләре Казан – Нократ Аланы поезды маршрутына үзгәрешләр кертәчәк. Состав ул көнне Арчага кадәр генә йөри, дип хәбәр итәләр ГТЮ корпоратив коммуникацияләр хезмәтеннән. Кизнер – Казан поездының да Курса – Әмәт станцияләре аралыгында расписаниесе үзгәрәчәк. Биектау – Бөреле станцияләре аралыгындагы юл эшләре 4 һәм 6 февраль көннәренә планлаштырылган. Бу көннәрдә Казан – Бөреле поездының маршруты Биектауга кадәр кыскара.

Фатир алырга уйласаң...

УЗГАН ел ахырында Татарстанда торак бәяләре күтәрелгән.

2012 елның дүртенче кварталында беренчел торак базарында 1 кв метр мәйданның уртача бәясе, өченче кварталга караганда, 0,5 процентка, икенчел торак базарында 5,1 процентка күтәрелгән. 2012 ел азагында беренчел торак базарында 1 кв метрның уртача бәясе 45441 сумнан артыграк булса, икенчел базарда 46437 сумга якын.

Казан шәһәре мэриясе, әнисе **Мөнирә Хәнәфи кызы САФИНА**ның вафат булуы сәбәпле, «Казаньцентрстрой» ААҖ генераль директоры Ринат Рәфкать улы Сафинның һәм аның якыннарының тирән кайгыларын уртаклаша.

ҖИР ҺӘМ КҮК

1-6 февраль магнит кыры тыныч булачак.

Бозлавыкта егылып, көн саен 30га якын кеше имгәнә

Казанда кыш башыннан 334 мең тонна кар чыгарылган, автомобиль юллары чиста. Ләкин тротуарларда тоташтан диярлек бозлавык хөкем сөрә.

ШӘҺӘР ХУҖАЛЫГЫ

Дамир БӘДРИЕВ

Шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Александр Лобов мәриядә узган киңәшмәдә: «Көн саен 552 кеше тротуарлар җыештыра», – диде. Әмма түрәнең бу сүзләре бер дә ышандырмый шул. Башкалада соңгы 2-3 атнада кар, гомумән, яумады. Мөңнәрчә кеше таптый торгач, тротуарлар, җәмәгать транспорты тукталышлары хәтәр бозлавыкка әверелде. Автобуслар туктый алмыйча 50-60 сантиметр шуып бара.

Эш төшеп, Азино тарафларына барырга туры килгән иде. «Казан-1» тимер юл вокзалы – «Кояшлы шәһәр» трамвай маршрутының Көньяк трасса һәм Җиңү проспекты өлешләрендәге тукталышлары кардан да көрәлмәгән хәтта. Трамвайга бозланган «тау»дан төшеп керәсең.

Җиңү проспекты белән Академик Глушко урамы киселешкән чаттан ук хуҗасызлык күзгә ташлана. Халык трамвай тукталышыннан Глушко урамына бозлавыклы «кәҗә сукмагыннан» узарга мәҗбүр. Тротуарлар юньләп җыештырылмаган.

Академик Глушко урамы белән Тыныч урамы киселешендәге чатта хәлләр тагын да яман. Күз алдында укучы балаларның икесе бозлавыкта егылды. Академик Глушко урамындагы бозлавыклы чат – бала арбалы хатын-кызлар өчен үтә алмаслык киртә. Шунлыктан алар автомобиль юлыннан барырга мәҗбүрләр.

Шәһәр башкарма комитетының сәламәтлек саклау идарәсе җитәкчесе Рамил Әхмәтов сүзләренә караганда, Казанда көн саен бозлавыкларда егылып, төрле авырлыкта имгәнүләр алып, 30лап кеше травматология пунктларына мөрәҗәгать итә икән.

Казандагы хуҗасызлык мисаллары турында административ техник инспекция идарәсенең **222-03-03** «кайнар элемтә» телефоны аша хәбәр җиткерергә мөмкин.

Алтын медальләргә юл сабый чактан башлана

Казанда муниципаль карамактагы балалар-үсмерләр спорт мәктәпләрендә 19 мең 853 бала шөгыльләнә.

УНИВЕРСИАДА СУЛЫШЫ

– Спорт мәктәпләренең 15е турыдан-туры Универсиада комплексларына урнашкан. Балалар «Тулпар», «Төзүче», «Мирас», «Москва», «Бустан» һәм «Олимп» спорт сарайларында да уку-күнегү дәресләре үтәләр. Яхшы шартлар куанычлы нәтиҗәләр дә бирә, – ди шәһәр башкарма комитетының физик культура һәм спорт комитеты рәисе Илгиз Фәхриев.

Узган ел, мәсәлән, Наталья Жукова яшьләр арасында чаңгыда узышта дөнья беренчелегендә ике мәртәбә чемпион исемен яулаган. Александр Марков физик мөмкинлекләре чикле спортчылар арасында җиңел атлетика буенча дөнья беренчелегендә җиңгән. Мария Шекерова дзюдо буенча Европа Кубогында бронза медаль, ә Светлана Липатова ирекле көрәш буенча Европа беренчелегендә 1 нче урынны алуга ирешкән. Халыкара спорт ярышларында Казаннан 27 үсмер егет һәм кыз катнашкан. Мәктәп яшендәге 20 бала халыкара классы спорт мастеры, 155е – спорт мастеры, 659 малай һәм кыз спорт мастерлыгына кандидат.

– Бу әйбәт күрсәткеч. Кызганыч, тренерлар саны җитми. Казанда быел – Универсиада, аннан спортның су төрләре буенча дөнья беренчелеге, футбол буенча дөнья чемпионаты көтә. Без балаларны шушы чараларга йөз төбәп, алтын медальләр яуларга рухландырып тәрбияләргә омтылабыз, – ди Илгиз Фәхриев.

ОЧТЫ-КИТТЕ

ӘЙТКӘН СҮЗ — АТКАН УК

Илсур МЕТШИН,
Казан мэры:

— Докладны тыңласаң, эш барышы һәрвакыттагыча бик яхшы, ә халык бозланган тротуарлардан зарлана.

(«Эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Александр Лобов докладыннан соң әйткән сүзләре)

КАСТИНГ

Җырчылар ярышты, чиратта биючеләр

6-7 февраль көннәрендә Казанда «Большие танцы» дигән яңа телевизион шоуга кастинг узачак.

Россиянең иң эре сигез шәһәрендә йөзәр кешедән торган командалар сайлап алыначак. Репетицияләрдән соң алар Мәскәүнең бию олимпын яуларга барачак. Проектта катнашучылар баш хореограф Пол Домейн җитәкчелегендә үзенчәлекле номерлар әзерләячәк. Хореографның Джордж Майкл, Тина Тернер, Шер, Кайли Миноуг кебек мәшһүр кешеләр белән эшләвен дә билгеләп үтәргә кирәк.

Сигез атна буена «Большие танцы»ны караучы тамашачыларга командалар иң популяр бию юнәлешләрен күрсәтәчәкләр. Һәр шимбә икешәр шәһәрнең коллективлары өч этаптан торган бәйгедә катнаша. Жюри әгъзалары һәм тамашачылар бергән бәяләргә карап, аларның берсе проекттан төшеп кала. Тамашачылар, гадәттәгечә, ошаган коллективлары өчен смслар җибәрер дип ниятләнелә.

«Сәхнәдә уйнау дулкын өстеннән йөзгән кебек»

Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, республиканың Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Нәҗибә Ихсанова белән тамашачы аның туган көнендә Г.Тукайның әдәби музеенда очрашты. Һәркемнең әлеге күренекле шәхескә җиткерәсе теләкләре, бирәсе сораулары шактый икән. «Тормышта еш кына үз-үземә мин кем? дигән сорауны биреп яшәдем», – дип башлады ул сүзен. Гомер буе театрда бәхетле артист, гаиләдә бәхетле хатын булып яшәвен дә яшермәде. Актер фикеренчә, иң зур бәхет: халкың белән бергә аңлашып яшәү. Кечкенә генә авылда туып үскән кызга актерлык һөнәрен сайлауда кем юл күрсәтүе белән тамашачы кызыксынмый калмады, билгеле.

ОЧРАШУ

Люция ХӘБИБУЛЛИНА

Нәҗибә апа шул чакларда үзе белән бергә югла чыккан авылдашы Әзһәр Шакировка гомер буе рәхмәтле булуын әйтте. Ә инде ямаулы киемнәр белән Мәскәүгә чыгып китүне батырлыкка тиңли артист. Мәскәүдә укып кайтканнан соң, сәхнәдәге тәүге роле булган А. Гыйләҗевнең «Көзге ачы җилләрдә»сендәге Гандәлифен дә искә төшерттеләр әлеге кичәдә. Билгеле инде, «Әлдермештән Әлмәндәр»дәге Өммия һәркемнең күңеленә кереп калган образ. Эпизод роле белән мәңгегә мәхәббәт уятырлык булып халык күңеленә керде шул Нәҗибә апа. Туфан абый әлеге әсәрне язганнан соң, аны укып чыккач, үзенә туры килердәй роль таба алмавын да искә алды ул. Тора-бара Өммияне иң яраткан роленә әйләнер дип кем уйлаган? «Сәхнәдә уйнау дулкын өстеннән йөзгән кебек. Кайвакыт бик тырышып уйныйсың, тамашачы кабул итеп җиткермәскә мөмкин. Киресенчә, кечкенә генә рольләр дә зур куаныч китерә, яратып калалар», – ди Нәҗибә ханым. Н.Ихсанова тудырган һәр образны караганда елмаясың да, уйланасың да. Ул башкарган Гөлфинә аналарга мактау булып яңгырый диминь, ни дисең. Кичәдә тамашачы аны экраннарда кабат искә төшерде. Шулай ук Нәҗибә апаның шәхси архивындагы фотолар аның тормыш мизгелләрен хәтердә яңартты. Ярты гасыр сәхнәдә берсеннән-берсе якты образлар тудырган артистка тамашачы рәхмәтен дә җиткерде.

– Туфан минем рольләремнән беркайчан да гаеп эзләмәде. Ул мине беренче планга куйды. Үзем дә Туфан язган әсәрләрне тамашачыга җиткерә алдым, – диде артист. Тамашачы театрның киләчәге белән дә кызыксынмый калмады. Монысына каршы Нәҗибә апа: «Театрыбыз ышанычлы кулларда. Фәрит Бикчәнтәев үзебезнең арада үскән егет. Ул безнең бәхетебез», – дип белдерде.

Койрыклар өши, үпкәләр кабара

ҺАВА ТОРЫШЫ

Илсөя ЗӘЙНУЛЛИНА

«Бүген төнлә 24 градус салкын була ди әнә. Әле кыш уртасында түгел, мартында да шарт дигәннәр борынгылар. Хут суыклары чыкканчы әле...» Урамда ике апаның шулай сөйләшеп торганын ишеткәч, интернеттан һава торышларын белешеп алырга булдым. Андагы хәбәрләргә караганда, бездә быел кыш беткәндәй дә «дөрес түгел» икән бит. Шәһәр читендә үз йортлары белән торучыларга, азык җитмәгәнлектәндер инде, төлкеләр дә кунакка килгәли ди әнә. Быелгы кышның холкы экологларны да аптырашта калдырган. Кар аз, көртләр тәбәнәк икән быел. Алга таба да шулай барса, туфракка дым җитешмәскә дә мөмкин. 2012-2013 елгы кышның үзенчәлекле булуыннан хайваннар да җәфа чигә. «Быелгы кыш бер җепшетеп, ул ара да түгел туңдырып, температура уйнатуы белән аерыла. Һава торышы 1-2 көн саен үзгәреп тора», – ди белгечләр. Мондый шартларда йортсыз этләр һәм мәчеләргә бигрәк тә авырга туры килә. Яңа туган эт балалары койрыкларын өшетә, үпкәләре кабарган, салкын тидергән, соң чиккәчә ябыккан хайваннар да бик күбәйгән. Бакчачылык белгечләренә төлкеләр ябырылган.

Зоопаркта да күпләрне аптырашта калдырган хәл булган. Кыш уртасында Кучум атлы көрән аю йокысыннан уянган. Торып бераз әйләнеп йөргәннән соң, карны тәмләп караган да яңадан ятып йоклаган үзе. Зоопаркта эшләүчеләр моны салкыннарның тиздән китәсенә юраганнар иде, әмма әле гыйнварның ахыргы көннәрендә Тимофей һәм Афанасий салкыннары буласы бар дип кисәтәләр. КФУның метеорология кафедрасы мөдире Юрий Переведенцев сүзләренә караганда, якын көннәрдә бернинди 30 градуслы салкыннар көтелми. Кыска вакытка температура төшеп алуны исәпкә алмаганда, билгеле. «Казанда – 15, республиканың төрле урыннарында 17 градустан да салкын булмас. Без хәзер антициклон тәэсирендә. Ә алар килгән Самара өлкәсендә купкә салкынрак. Алга таба һава массалары көнбатыштан көнчыгышка хәрәкәт итәчәк һәм безгә көнбатыштан җылы һава киләчәк», – дип тынычландыра ул.

Гарип бала асрасаң...

ВАЗГЫЯТЬ

Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ

Бу ел Россиядәге авыру ятим балаларны АКШка асрамага бирүне тыя торган канунның имзалануы белән башланып китте һәм киң җәмәгатьчелектә зур шау-шу тудырды. Нәтиҗәдә хәзер түрәләребез инвалид ятим балаларны асрамага алучы гаиләләрне йөз мең сум күләмендә акча белән кызыктыру хакында уйлана. Әлегә исә бу сумма 13 мең сумны тәшкил итә. Күптән түгел Россиянең Мәгариф һәм фән министрлыгы шундый инициатива белән чыкты. Мондый инициатива тормышка ашырылса, балалар гаиләле була алырмы, әллә кемнәрдер ятимнәрне акча янчыгын үзләштерер өчен генә кирәксенерме?

Түрәләр фикеренчә, ятимнәрне уллыкка алучыларның торак мәйданына бәйләнү дә урынсыз. Бу очракта төп игътибар санитария һәм техник нормаларга юнәлдерелергә тиеш. Балалар хокукы буенча РФ Президентының вәкаләтле вәкиле Павел Астахов әйтүенчә, һәр өлкәдә асрамага алучылар мәктәбе булырга тиеш. «Кеше анда укый һәм имтиханнарны, тестларны уза икән, аны моның өстенә бер көтү кәгазь дә җыеп йөрүдән азат итәргә кирәк. Шуңа күрә, алар укыган арада, кәгазьләрне кемдер инде әзерләп куярга бурычлы», – ди Астахов.

Йөз мең сумлык пособие ул, әлбәттә, асрамага бала алучылар өчен 13 мең сумлык пособие белән чагыштырганда бик әйбәт стимул. Әмма бу пособие әлегә инвалидларга һәм 10 яшькәчә булган балалар өчен генә карала. Аның каравы, бу эшкә әле җирле хакимият тә үз өлешен кертә ала. Мәсәлән, ТР Министрлар Кабинеты быел республиканың Дәүләт Советына асрамага алган беренче бала өчен акча түләү турындагы канун проектын тәкъдим итәргә җыена. ТР Дәүләт Советы Секретаре Лилия Маврина җиткерүенчә, моннан тыш опекуннар һәм попечительләргә дә бүләкләү күләмен арттыру мәсьәләсе карала икән. Ә ТР прокуроры Кафил Әмиров исә еш кына үги балаларны җәберләү, кочләү, тәрбияләүдән баш тарту, ашатмау кебек җинаятьчел күренешләрнең арту куркынычы булуын кисәтә.

Канунга үзгәрешләр кертү хакында әлегә фикер алышырга була. Кабул ителә калса, бу документ тәрбиягә бала алучылар өчен яңа гарантияләр белән тулыланырга мөмкин. Тәкъдимнәр февральдә Дәүләт Думасына тапшырылыр дип көтелә.

АЙНУР ГАЛИМОВ

Урын өчен кансыз көрәш

Тарих дәресләрендә өйрәнгәннәрдән патша заманнарында дәүләт перевороты дигән күренеш «модада» булганын беләбез. Мөмкинлеге булган һәркем патшаны бәреп төшереп, аның тәхетенә менеп «кунаклый» алган. Узган гасырның 90 нчы еллары өчен дә «урын бушату» ысулы, ягъни үтерү, кыйнау, көчләү, гаиләсенә янау, шантаж алымнары белән югарырак пост биләүче затның «җылы» кәнәфиен үзләштерү гадәти хәл булган. Бу кыргый заманнар артта калган иде кебек тә бит, әмма…

Җитәкче кәнәфие «татлы»

Мәскәүнең Зур театрының сәнгать җитәкчесе Сергей Филинның йөзенә кислота сибүләре турында ишетми калганнар юктыр арабызда. Бу хәлгә ике атна вакыт узуга карамастан, әлегә җинаятьченең исеме дә, һөҗүмнең төгәл сәбәпләре дә билгеле түгел. Тикшерү тарафыннан хәзерге вакытта алга сөрелгән җинаять мотивларының иң төбе артистның һөнәри эшчәнлегенә, аның биләгән урынына бәйле. Бу турыда интервьюларында Зур театрның генераль директоры Анатолий Иксанов та кат-кат әйтә: «Бу хәлнең Филинның җитәкчелек кәнәфиеннән баш тарттырырга тырышулары булганын мин 100 процент ышаныч белән әйтә алам».

Җинаятьнең нигезендә «татлы» урынга күз атулары ятканы белән театрның башка хезмәткәрләре дә, бөтен сәнгать эшлеклеләре дә, криминалист-психиатр Михаил Виноградов та килешә. Аның сүзләренә караганда, кислотаны корал буларак файдалана башлау узган гасырның 20 нче елларыннан ук таралыш алган һәм ул бик еш театраль мохиттә, йөз-кыяфәтләре һөнәри эшчәнлекләренең нигезен тәшкил иткән даирәдә кулланыла.

Зур театр исә сәнгать осталыклары белән сату итүчеләр өчен аеруча калын итеп бал сыланган урын. Дөньякүләм данлыклы булуы аркасында, анда һәр урын, һәр роль өчен җитди көрәш, зур конкуренция бара. Ә Филинның бик гадел җитәкче булуы билгеле һәм рольләрне ул беркемне дә үпкәләтмәслек итеп түгел, һәркемнең талантына карап бүлә торган булган. Башта Филинга янап, машина тәгәрмәчләрен тишеп, интернеттагы почта әрҗәләрен ватып йөргән, ахыр чиктә, кислота сибеп йөзен шыксызландырган, әздән генә сукырайтмаган җинаятьчене тикшерүнең шул үпкә саклаганнар һәм урынына кызыкканнар арасыннан эзләү бик дөрес. Хәзер театр артистларын ялган детекторында тикшерә башладылар.

Баш мие Мексикада калган

Россиянең мәдәният һәм сәнгать дөньясында артистларны куркытулар, аларны компроматлар белән шантажлаулар, театр директорларына янаулар әллә ни сирәк күренеш тә түгел. Вакытында «Геликон-опера» театрының сәнгать җитәкчесе Дмитрий Бертманга театр бинасын реконструкцияләү мәсьәләсендә җитди янаулар булган. 2011 елда интернет челтәрендә балет труппасы җитәкчесе Геннадий Янинны фаш итүче мәгълүматлар калкып чыккач, артист эш урыныннан очты. Узган елның ноябрь аенда Мексика төрмәсендә җан биргән «Кояш циркы» артисты Антон Алферовның сәер үлемен дә бәлки шул «урын өчен көрәшкә» бәйләргә буладыр.

Мексика экспертлары сүзләренә караганда, административ җинаять өчен кулга алынган Алферов камерада башка тоткыннар белән сугыша башлаган, шул сәбәпле аны хастаханәгә озатканнар. Әмма ул медицина ярдәменнән баш тарткан һәм кире камерага кайтарылгач, үз-үзенә кул салу нияте белән стеналарны, рәшәткәләрне башы белән төя башлаган, хәтта унитазны да ярган. Ахыр чиктә, ул янә хастаханәгә юнәлтелгән һәм анда баш мие җәрәхәтеннән үлгән. Күптән түгел Алферовның җәсәден Россиягә кайтардылар, әмма артистның баш сөяге буш булып чыкты. Аның үлеменә ачыклык кертергә тиешле төп әгъзасы – баш мие Мексикада калган. Россия экспертлары Мексикадагы хезмәттәшләре эшеннән шикләнә башладылар. Артистның баш миен үзләрендә калдырулары мексикалыларның җинаять эзләрен яшерергә тырышуларына бәйле булуы бик мөмкин. Тикшерү бу версияне алга сөрмәсә дә, артистның иптәшләре арасында аның үлемен һөнәри эшчәнлегенә бәйләүчеләр бар. Янәсе, тәҗрибәле акробат, Мексикада шәхси шоуын булдырырга йөргән егет «Кояш циркы»нда кемгәдер комачаулаган.

Сәхнәдә конкуренция һәрчак булган. Әмма көнләшүчаткылары берәр артистның чыгышы вакытында будильник яңгырату, аяк астына үлгән мәче ату, бию аяк киемнәре эченә пыяла кыйпылчыклары салудан ерак китмәгән. Соңгы хәлләрдән чыгып, кыргый заманнарга кире кайтмабыз, дип кем ышанып әйтә ала?

Авыл табиблары фатир сайлый

Узган ел, яшь белгечләрне авыл җиренә кайтару максатыннан, «Земский доктор» дип аталучы федераль программа гамәлгә кергән иде. Аның нигезендә дәүләт 5 ел дәвамында авыл җиренә кайтып эшләргә ризалык бирүче 35 яше тулмаган табибларга 1 миллион йөз мең сум күләмендә субсидия өләште. Бу акчалар торак мәсьәләләрен яхшырту максатын күздә тотты. Авылга бер кайтуымда: «Безнең якларда әлеге программага мөнәсәбәтле эшләр ничек бара икән?» – дип кызыксынырга район үзәк хастаханәсенә барып килдем.

КАЙГЫРТУ

Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ,
Чирмешән

«Земский доктор» үз эшен эшләде

Чирмешән районы үзәк хастаханәсенең баш табибы Гайсә Сәгыйров җиткерүенчә, узып киткән елны районыбызда 9 фельдшер-акушерлык пункты ремонтланган, 2 табиб амбулаториясенә һәм бер участок хастаханәсенә капиталь ремонт ясалган икән. Соңгы елларда районыбыз авылларындагы җирле хастаханәләрнең төрле сәбәпләр белән эшләүдән туктавын ишетеп йөрәк әрни иде, ә бу хәбәрләр күңелне күтәреп, сөендереп җибәрде. Ни дисәк тә, авыл җирендә яшәүче һәр кеше атлаган саен үзәк хастаханәгә барып, кадерле вакытын чиратта үткәреп кайта алмый бит. Хәер, соңгы елларда район үзәк хастаханәсе үзе дә шактый матурайган, күп нәрсә яңартылган, уңайлырак итеп үзгәртелгән. Мәсәлән, биш миллион ярым сум республика бюджеты һәм бер миллион сум район бюджеты хисабыннан кабул итү бүлеге төзелгән. Алга таба өч катлы бинага лифт кую да каралган. Һәм, әлбәттә, үзәк хастаханәдәге кадрлар составының шактый яңаруы, яшәреп китүенә игътибар итмичә була торган түгел. Бүген биредә штатта 313ләп эшче исәпләнә, шуларның 31е табиблар. Бишесе яңа гына әлеге дә баягы «Земский доктор» программасы буенча эшкә килгән икән.

«2011дә үк терапевт булып эшләргә кайткан үз районыбыз кешесе Денис Егоров бу дәүләт субсидиясенә инде ике бүлмәле фатир сатып алырга да өлгерде. Баулыдан хирург Айгөл Гыйззәтуллина күчеп килеп эшкә урнашты. Үзебездә эшләүче эпидемиолог Лаешка китеп барган иде, аның урынына Лениногорскидан Эльмира Минһаҗеваны алдык. Моңарчы Чистайда эшләгән гомумпрактика табибы Евгения Островская район егетенә кияүгә чыгып безнеке булды. Иң соңгы булып Түбән Камадан ирле-хатынлы Кәлимуллиннар гаиләсе эшкә килде. Ире Әмир – теш табибы, хатыны Елена психиатр-нарколог булып эшли. Бу гаиләгә һәм хирургка әлегә яшәп торыр өчен икешәр бүлмәле эш фатирлары тапшырдык. Хәзерге вакытта безгә рентген буенча гына белгеч кирәк. Әлегә таба алмыйбыз. КГМУда максатчан укыту программасы нигезендә 9 студентыбыз укый. Шуларның икесе киләсе елда уку йортын тәмамлаячак», – диде 36 ел гомерен медицина өлкәсенә багышлаган, соңгы 15 елында Чирмешән үзәк хастаханәсенең баш табибы булып эшләүче Гайсә Сәгыйров.

Күчемсез милек әрәм булмый ул

Гайсә Галим улы таныштырган белгечләр арасында минем өчен иң кызык табылганы Кәлимуллиннар гаиләсе булды. Үзләре белән танышырга дип, «теш терапиясе» бүлмәсенә юл тоттым. Татарча аңласа да, русчалап җавап кайтаручы яшь белгеч мине ашыгыч рәвештә психиатрга озату ягын карады. Психиатр дигәнем аның хатыны Елена булып чыкты. Елена ханым хатын-кызлар бүлегендә сәламәтлеген ныгытып ята икән. Без аның палатасында гәпләшеп утырдык.

Яшь гаиләне Ижау медицина академиясе таныштыра, кавыштыра. «Без тугыз ел дәвамында очрашып йөрдек, аннан ирем 3 ел буе укып бетерүемне көтте», – дип сөйли яшь белгеч. Өйләнешкәч тә алар Түбән Камага барып урнаша. Дөресрәге, Әмир анда инде өч ел эшләгән була. Нефть химиясе төбәгендә яшь гаилә ике ел яши. Әмир теш табибы булып «Стомус» клиникасында һәм шәһәрнең бер стоматология дәваханәсендә, ә Елена исә Түбән Каманың наркология һәм психоневрология диспансерларында эшли. Яшь гаилә бер-берсе белән күрешергә дә вакыт таба алмыйча, кичке дежур торуларга кала-кала, күп дигәндә атнага ике тапкыр очрашып, алны-ялны белмичә эшли. Шулай итеп, әти-әниләре ярдәме белән яшьләр Түбән Камадан фатир алурга да ирешә. Ә беркөнне Әмирнең дусты «Стомус» дәваханәсен ташлап «Земский доктор» программасы буенча, Тукай районына эшкә кайтып китә. Аның үрнәгендә Кәлимуллиннар гаиләсе дә бәхетен сынап карарга уйлый һәм ТР Сәламәтлек саклау министрлыгына шалтырата.

«Бирегә килгәч, без тулы гаилә булып яши башладык. Бер үк хастаханәдә эшләгәч теләгән вакытта күрешә алабыз, бер-беребез өчен вакытыбыз җитә. Дәүләттән алынасы акчага берәр шәһәрдән фатир алырга җыенабыз. Әлегә кайдан аласын уйлап бетермәдек. Йә Казаннан, йә Ижаудан алырбыз, мөгаен. Без биредә биш ел эшләргә бурычлы. Яшәп торырга эш фатиры бар, ә алдагысын күз күрер. Күчемсез милек әрәм булмый ул. Ә Чирмешәндә безгә бик ошый. Тыныч, рәхәт монда», – дип сөйләде татар егетенә кияүгә чыккан әтисе ягыннан – мари, әнисе ягыннан удмурт булган яшь психиатр.

Уңыш һава торышына бәйле

ТИКШЕРЕНҮ

Сөләйман НӘҖМИЕВ

Соңгы еллардагы табигатьнең гаять көйсезләнүе һәм сәер галәмәтләре авыл хуҗалыгындагы галимнәрне дә аптырашта калдырды. Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты директоры Марсель Таһиров фикеренчә, хәзер һава торышына бәйле рәвештә аграр тармакта төгәл генә нәтиҗә ясау мөмкин түгел. «Мисал өчен, Казанда бүген 15 градус салкын булса, шул ук вакытта без тикшеренүләр алып барган Олы Кабан җирлегендә температура 22 градуска кадәр төште. Язын да республикада җирләр төрле районда төрлечә өлгерә. Шуңа да безнең галимнәрнең иген культуралары сортлары уйлап чыгару буенча тагын да ныклап шөгыльләнүләре сорала. Һәм алар бу юнәлештә нәтиҗәле эшлиләр дә», – ди директор.

Күптән түгел фәнни-тикшеренү институтында узган очрашуда галимнәр соңгы елларда тармакта алып барылган эшчәнлекләренә кайбер нәтиҗәләр ясады. 20 елдан артык бу өлкәдә эшләгән галим Олег Шайтанов билгеләп узганча, табигатьтә соңгы 2 елда җылыну процессы башланды һәм фаразлар буенча ул алга таба да дәвам итәчәк. «Яз иртә килә, көз озын. Шуңа күрә вегетация чоры да зуррак була. Моңа бәйле рәвештә соң өлгерә торган культуралар да игәргә мөмкин. Ләкин әлегә бу барып чыкмый, чөнки явым-төшемнәр күләме язын, җәен азрак, ә кышын ул күбрәк. Туң катламы да тирән түгел хәзер. Кыш соң килә, җир тиешенчә катып өлгерә алмый. Болар барысы да көзге культураларның начар кышлавына китерә. Һәм шуңа да селекция белән эшләүчеләр алдында тагын да зур бурычлар тора», – дип ассызыклап узды галим. Әлбәттә, институт галимнәренең уңышлары инде ил күләмендә билгеле. Быел гына да алар тарафыннан аграр культураларның 7 яңа сорты уйлап чыгарылган. Хуҗалыклар белән узара фикерләшеп эшләү тәҗрибәсенә килгәндә, биредә институт галимәсе Александра Фадеева эшчәнлеге игътибарга лаек. Галимә сүзләренә караганда, соңгы елларда аксымга бай культураларны игүгә зур әһәмият бирәләр. Борчакның аеруча «Труженник», «Таң», «Венец», «Ватан», «Указ», «Варис», «Казанец» кебек сортлары күпләп игелә икән. Сабагы кыска, егылмый торган төрләргә өстенлек бирергә тырышалар хәзер. Татарстанда борчактан уртача 19ар центнер уңыш алган хуҗалыклар да бар. Хәзер «Кабан» исемле яңа сорт өстендә эшлибез», – ди Александра Фадеева.

Институт галимәләре Нурания Василова һәм Ирина Фадеевалар да республикада игелә торган сабан культуралары һәм көзге бодайның аеруча зур күләмдә игелә торган сортларына тукталдылар. Ә инде быел уҗымнарның торышына килгәндә, галимнәр искәрткәнчә, әлегә төгәл генә берниди дә нәтиҗә ясап булмый. Язның ничек килүе дә йогынты ясаячак көзге культураларга.

Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты бүгенге көндә республикадагы төрле формадагы 1 меңнән артык хуҗалык белән эшне җайга салган. Галимнәр фикеренчә, еш кына «ашлаган җир аш бирә» дигән әйтемне онытучылар белән очрашырга туры килә. Җирнең уңдырышлылыгын арттыру өчен, тиешле ашламасын да дөрес итеп кертә белергә кирәк. Сидерат өчен кулай культуралардан клевер, рапс кебек үләннәрне дә чәчү зарур. Туфракның торышын да даими тикшереп тору сорала. Институт белгечләре нәкъ менә шул проблемаларны чишү өстендә эшлиләр дә инде.

НИХӘЛ, АВЫЛ?

Бал гына ашап торачакбыз

Татарстанда быел бал кортлары гаиләләрен 235 меңгә кадәр арттыру планлаштырыла. Ул вакытта товар балын җитештерү 5 мең тоннага кадәр артачак. Үткән елда республикада 224 мең бал корты гаиләсе исәпләнгән. Балның тулай күләме 3600 т тәшкил иткән. Умартачылык буенча идарәдә хәбәр итүләренчә, республика халкы өчен продуктның мондый күләме җитми. Белгечләр дә, тармакны тизрәк үстерү өчен, резервлар бар дигән фикердә тора. Үткән елда шәхси хуҗалыкларда умарта гаиләләре саны исә 170,5 меңнән 187,3 меңгә арткан.

Яшел Үзәндә казылык эшлиләр

Яшел Үзән районында ит эшкәртү цехы ачылды. Яңа предприятие «Авангард» ЯАҖ базасында эшли башлады. Цех казылык эшләнмәләренең 20дән артык төрен чыгаруга исәпләнгән. Агымдагы елда предприятие җитәкчелеге 500 тонна продукция җитештерергә планлаштыра. Ит эшкәртү эшен ун кеше башкара. Киләчәктә эш урыны тагын унга арттырылачак.

Терлекчеләр тәҗрибә уртаклаша

Бөгелмә районы Кодаш авыл җирлегендә Муса Җәлил исемендәге хуҗалыкта терлекләрнең ничек кышлавы мәсьәләләренә багышланган семинар-киңәшмә булып узды. Семинарда катнашучылар районның Харис Әхмәтгәрәев җитәкчелегендә аеруча уңышлы эшләп килүче Муса Җәлил исемендәге хуҗалыкның товарлыклы сөт фермасында булдылар. Бу агропредприятиедә терлекләрне асрау нормалары саклана, терлекчеләргә тиешле эш шартлары да булдырылган. Агрохуҗалыкның уңышлы эшләп килүе аның финанс яктан имин булуы белән дә дәлилләнә. Бүген хуҗалыкта 7 мең гектар чамасы сөрүлек җир исәпләнә, узган 2012 елда 13 мең тонна ашлык суктырып алганнар. Фермаларда 1204 баш мөгезле эре терлек, 2400 баш дуңгыз, 200 ат бар. Агропредприятиенең узган елдагы гомуми кереме 58 миллион сум тәшкил иткән.

Сәхифәне
Чулпан НӘҖИПОВА
әзерләде

Казан кебек миллионер шәһәрдә фатирлы булу лотерея билетында джекпот оту белән бер. Бигрәк тә хәзерге чорда бу сүзләрнең дөреслегенә шик белдереп булмый. Авылдан килеп укыган, соңрак монда эшләп калганнар өчен фатирлы булу аеруча зур хыял. Бу хыялны тормышка ашыруның иң реаль формасы булып ипотека тора. Шуңа да без дә аннан читтә кала алмадык. Ипотека дәүләт программасы буенча бирелгән фатирлар турында ишетеп йә укып кына белә идем. Хәзер, шушындый фатирда бер еллап яшәгәннән соң, әлеге хакта үзем дә бик күп сөйли алам.

«Ошамаса, аерым йорт алыгыз!»

Айсылу ИМАМИЕВА

Беренчедән, бу җиңел генә бирелә торган үр түгел. Фатирга чиратка бастырсыннар өчен чиратка басу, аннан шул төп чират номерын алгач, еллар буе конкурста отуыңны көтү... Кыскасы, сез мине аңладыгыз. Менә шул озын юлны үткәннәр, ниһаять, ачкычларын кулларына тотып, үз бусагаларыннан атлап керәләр. Бу очракта сүзем читтән махсус ярдәм булып яисә эшләре аркылы (целевиклар) тиз арада фатир алганнар турында бармый.

Без дә 2011нең җәендә фатирлы булдык. Сөенечнең чиге юк инде. Тугыз ел буе тулай торак һавасын сулаганнан соң, монда сулыш алуы күпкә иркенрәк. Бер генә бүлмә булса да – үзеңнеке. Йортыбыз – кызыл кирпеч белән тышланган газобетоннан төзелгән, пластик тәрәзәләр куелган ун катлы шәһәр өе. Документларда ни өчендер ул тулысынча кирпечтән һәм агач тәрәз-рамнар куелган дип язылган. Элегрәк, пластик тәрәзәләр модага кергән вакытта, алар кыйммәтрәк йөрсә, хәзер бит, киресенчә, агачларының бәяләре югары. Әллә безнең йорт төзелә башлаганда агачлары очсызрак булып, бүгенгә килеп җиткәндә аларына акчалары җитмәдеме икән? Мөгаен, шулайдыр. Ә менә йортны тулысынча кирпечтән дип язу кемгә кирәк булгандыр? Фатирның болай да аз булмаган бәясен ничек тә арттырырга белмәгәннәндер инде анысы. Ишекне дә тимердән дип язганнар, әмма аның калынлыгы ташка үлчим. Тиз арада алыштырмасаң, тибеп кенә дә ачып керүләре бар. Беренче кат булгач, аеруча шүрләтә, аннары фатир эчендә уйнаган җил дә эчне пошыра. Кыскасы, ишекләрне ике атна дигәндә барлык фатирларда да алыштырып чыктылар. Шулай ук аш бүлмәләренә куелган, үзебезнең Татарстанда ясалган «Идел» плитәләре дә канатланды. Ул вакытта шатлык хисеннән нишләргә белгән юк, бернәрсәгә дә игътибар итмибез.

Йә ярый, яшәп киттек без, танылган юмор остасы Рафис Фазылҗан әйтмешли, пипотека-математика фатирында. Баштагы мәлдә йорттагы тәрәзәләрнең берничәсендә генә утлар кабына иде. Озакламый эштән кайтуга, безне дрельләр, дюбельләр, болгаркалар, чүкеч-пычкылар хоры каршы ала торганга әйләнде. Күпләрнең дәүләт ябыштырган обойларга, җәйгән линолеумнарга исе китмәде. Фатирларның сиксән процент өлешендә евроремонт эшләре башланды. Ул тавыш шимбә-якшәмбе көннәрендә дә тынмыйча, яшәү рәвешенең бер өлешенә әйләнеп китте. Шуны да искәртеп үтим – ипотека йортларында тавыш изоляциясе ноль дәрәҗәсендә. Һәрхәлдә, безнең йортта шулай. Күршеләрнең нәрсә сөйләшкәннәре, нинди музыка тыңлаганнары, тузан суыртканнары, ванна кергәннәре рәхәтләнеп ишетелеп тора, плюс теге хорны да өстәсәң... Чынлап әйтәм, моннан кырыкилле ел элек төзелгән тулай торакта да бу хәтле тавыш ишетмәдем. Кирпечтә генә түгел, изоляция материалларында да, сантехникада да экономия ясаганнар булып чыкты. Ник экономиялиләр диген, барыбер безгә түлисе бит инде аны. Теге тавыш дигәннәре шактый халык күченеп беткәч тә тынмады. Яз җитеп, бәбиебез тугач, көннәр дәвамында тынмый торган хорга чынлап торып аптырый башладым. Бала йоклап кына китә, тотына бит теге дрель үз «җырын» үкертергә. Кайсы көннәрдә кичке унбергә кадәр туктый алмыйлар. Аптырагач, һәр этаж саен тикшереп чыктым. Бер фатирда инде икенче тапкыр евроремонт ясыйлар икән. Өченче хуҗага икенчесе ясаганы ошамаган, ә фатирга мохтаҗ беренче хуҗаның кем икәнлеген инде белүче дә юк. Бер фатирга ремонт ясаучы ял көннәрендә генә килә ала. Ашыкмый гына, яратып кына ремонтлыйм фатирымны, дип елмая ул. Кызык, кемнәрнеңдер яшәргә урыннары юк, фатир чиратларын көтеп җиткерә алмый тилмерәләр. Ә бу? Күренеп тора, аның фатирга мохтаҗлыгы шуның кадәр генә. Мөгаен, ремонтлап бетерүгә үк ул анда кемнәрнедер яшәп торырга кертер. Йорттагы фатирларның яртысында диярлек төп хуҗаларга акча түләп торучылар яши, русчалап әйткәндә, фатирларны «снимать» итәләр. Безгә каршы фатир хуҗасы Төркиягә эшләргә китеп барган, ә фатирын балалы бер парга калдырган. Алары ай саен ун мең сум акча түләп тора. Теге кызый чит илләр белән хозурланганда, фатирының ипотекасы да түләнә. Ярар, төп сүзем бит тавыш хакында. Берике айдан ремонтны бетерәбез, дип сөйләнгәннәр үз вәгъдәләрендә торыр да бу тавышлар тынар дидем. Сабыр итәргә туры килде. Теге ремонт фатирларында чыннан да эшләр төгәлләнде. Әмма тавышлар туктамады. Мин инде, йортка күчкәнгә бер ел тулды, нәрсә соң бу, дип тәмам шаккаттым. Әллә, мин әйтәм, берәр фатирда йорт җиһазы ясаучы цех ачып куйганнармы? Кайсыдыр йортларда шулай легаль булмаган чәч кисү яки массаж салоннары, тегү цехлары ачалар дип сөйләп торалар бит. Шуңа, түзмәдем, участок полицейскиен чакыртырга булдым. Килсен, ишетсен, тикшерсен дигәндәй... Әлбәттә, ул кеше бер чакыруда гына килмәде. Икенче көнне дә шалтыратырга туры килде. Ниһаять, күрештек без аның белән. Алдагы көнне ник килмәгәнен сорагач, ул миңа үтә дә мыскыллы караш ташлап, утырырга урындык сорады. Минем сорау аңа бик мәгънәсез тоелды булса кирәк. Шуннан минем зарларымны түкми-чәчми кәгазьгә яза-яза тыңлады да: «Сез нәрсә?! Кайдан килсен монда цех, фатирларын ремонтлыйлар. Бөтен кеше дә сезнең кебек мондый обой белән яшәп ята дип уйлыйсызмы әллә?» – дип тезеп китте. Мин аңа фатирларда ремонт беткәнлеген әйткәч, ул ачуыннан кабара ук башлады. «Алай бик акыллы булгач, яшәмәгез күпкатлы шәһәр фатирында. Әнә шәһәрдән читтә үзегезгә өй сатып алыгыз», – дип, сүзен төгәлләде. «Закон нигезендә төнге уннан соң шаулашырга ярамый, ә ремонт эшләрен тугызга кадәр генә уздыру рөхсәт ителгән, эзләп карагыз инде, бәлки, чыннан да цех бардыр», – дигәнгә берни эндәшмәде. Ниндидер кәгазьләргә кул куйдырды да ишекне шапылдатып чыгып китте. Өй сатып алыгыз, дип «акыллы» киңәш бирүенә ачуым кабарса да, артык телләшә алмадым. Булгандырмы ул цех, юкмы, әмма, бәхеткә, шуннан соң теге тавышлар башка кабатланмады.

Бер ел дигәндә фатирыбызның ванна һәм аш бүлмәләрендә сантехника сафтан чыга башлады. Аны ремонтлау өчен аерым акча түләргә кирәк булганлыгын белү дә мине шаккатырды. Сантехникны өйгә чакырту өчен, идарәдән махсус квитанция алу, аннары шул ике йөз сумны банкка түләү мәҗбүри икән. Бу бер дә дөрес түгел, без бит ай саен ремонт дигән графа буенча акча түлибез, дигәч, миңа, сезнең күзегез бармы, дигән сорау бирделәр. Үпкәләмәдем, мондый мөнәсәбәт миңа инде гадәти тоела башлады. Күзләремне зуррак итеп ачып укырга кирәк булганлыгын ишеткәч, трубканы куйдым. Ай саен агымдагы ремонтка түләвебез ул гомум йорт чыгымнарына гына кагыла икән. Күптән түгел генә кабул ителгән кагыйдә нигезендә, фатирдагы ремонтлар өчен аерым түлисе ди. Менә шулай гел халыкка «ярдәм итәргә» атлыгып торган идарәче компания хезмәткәрләренең уйлап чыгару сәләтенә шаклар катасың. Дөньядагы иң оста әкиятчеләрне дә уздырып кагыйдәләр уйлап чыгара бит алар. Тик аларның нәрсәгә нигезләнгәнен сорасаң, берәү дә аңлатмаячак. Шуңа да, артыгын аңламыйча гына, булганына шөкер итеп яшәп ятабыз.

Бер ел дигәндә, ипотека-пипотека фатирларының менә шундый сыйфатлары ачылды. Әле алда тагын нәрсәләре белән сөендерәчәген вакыт күрсәтер. Шулай да, нинди генә булсалар да, төзелеп торсыннар иде алар, дип телисе килә. Гади халыкка аз булса да ярдәм бит шул ипотека дигәннәре. Иң мөһиме – аның бәясен, процентларын куйганда һәм төзелеш материалларын экономияләгәндә чикчаманы онытмасыннар иде. Калганнарына күз йомып, күрмәмешкә дә салышып була.

Алисә САБИРОВА

Һәркемнең үз матурлык кануннары

Теле ачыла башлаган бала да матурлык кануннарының 90-60-90 икәнен белә. Бу гаҗәпләнерлек тә түгел, газета-журналларыбыз, телевидение көн дәвамында безгә моның турында тәкрарлый. Мода үзгәргән саен, яңа күлмәк, матур прическа, йөзебездә берничә катлам «штукатурка»...

Матур булу өчен гүзәл затларыбыз нинди ысуллар гына кулланмый. Матурлыкны барыбыз да яратабыз, аңа сокланабыз. Матур булу – үзе бер сәнгать бит ул. Менә шундый бер сәнгать «экспонаты» белән миңа да танышырга туры килде.

Автобус тукталышында басып торам. Яныма бер кәттә генә кыз килеп басты. Кышкы салкын көн булса да, озын кара чәчләре биленә кадәр төшкән. Ислемае теләсә кемнең башын әйләндерерлек. Матур кашлар, алсу иреннәр, гомумән, туташның йөз-кыяфәтенә тел-теш тидереп булмый. Бар да зәвык белән сайланган. Гламур журналлардагы фотомодельләрдән ким түгел. Әлбәттә инде, кыз килеп басуга, бар егетләрнең игътибары аңа юнәлде. Кызлар да кызыксыну катыш көнләшү аша аны күзләре белән «ашады». Ләкин матурлык белән хозурлануыбыз озак бармады. Кызның телефоны шалтырады. Менә шунда белдек тә инде «кәттә»нең чын йөзен. Телефонны алырга да өлгермәде, бар тукталышка «матур-матур» сүзләр белән әңгәмәдәшенең кемлеген, аңа кая юнәлергә кирәклеген шар ярып салды. Кыз, янындагы ак яулыклы карчыкларга, олы абый-апаларга, сабыйларга игътибар бирмичә, сүгенү сүзләрен яудыра барды. Колакларны «иркәли» торган мондый сүзләрне минем базар хатыннарыннан гына ишеткән бар иде. Ләкин «сүз байлыгы» ягыннан кыздан әле алар да калыша. Бер-ике минутлык бу әңгәмәне тыңлап торган әбиләр тизрәк автобусларына керергә ашыкты, егетләр исә моннан ераграк торырга кирәк дип, ахры, читкәрәк китеп басты. Кыз телефонын куйды да янә матур елмаю белән балкырга тотынды. Ләкин инде аңа сокланучы да, кызыксынучы да юк иде.

Әйе, матур булу ул – үзе бер сәнгать. Ләкин сәнгать җанлы булырга тиеш. Ботоксларга баткан, тышкы кыяфәтен кайгыртып күпләп акча түккән, ләкин эчке дөньясы бер тиенгә дә тормаган ханымнарны матурлар рәтенә кертмәс идем мин. Теләсә нинди бизәнү чарасы да кызларның йөзендә балкыган иман нурын, тәүфыйклылыкны, сафлыкны алыштыра алмый шул.

Урамнан барганда юлыма «ашыгыч ярдәм» машинасы очраган саен, күңелемнән әйтергә ашыгам: «Йа Ходам, бу бәндәңә җиңеллекләреңне бирсәң, ярдәмеңне салсаң иде». «Ашыгыч ярдәм» дигәннәре ярый ла вакытында килеп җитә алса, дип тә борчыла күңел… «Әйдә, берәр көн безнең белән йөр, үзең күрерсең, ярдәм дә итәрсең, нәтиҗә дә ясарсың», – диде шушы өлкәдә эшләүче танышым. Читятларның күзенә бик чалынмый гына машинага кереп утырдым.

Безгә АШЫГЫЧ ЯРДӘМ кирәк!

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА

Фото бизәү өчен бирелә

Табиб алга урнашты, без исә фельдшер егет белән машинаның артындагы урыннарга урнаштык. Фельдшер егет Рөстәм медицина көллиятен тәмамлаган, хыялы киләчәктә медицина университетына керү. Ләкин мәктәптән соң киләсеңме син, көллиятне тәмамлап, берәр ел эшләгәч, югары белем алырга ниятлисеңме – укырга керү шартлары бар кеше өчен дә бер. Моңысы мине бик гаҗәпләндерде. Ничек инде башлангыч белеме, иң мөһиме практикасы булган, үзен бу эштә сынап караган кешегә өстенлек бирелми. «Юк», – ди Рөстәм. Ул инде белешкән, исәбе киләчәктә кредит алып, түләүле бүлеккә булса да укырга керү. Менә шуннан соң әйт инде син үз эшенең фанатлары юк дип. Хезмәт хаклары узган елның август аенда бераз арткан икән. «Ашыгыч ярдәм» табиблары һәрвакыт җитми, шуңа күрә мин өстәмә сменалар да алам, шулай иткәндә айлык хезмәт хакы да ярыйсы чыга», – диде Рөстәм.

Бер исереккә— алты дәүләт кешесе

Матур гына гәп корып барганда, табибның: «Рөстәм, перчаткаларны әзерлә!» – дип эндәшүе сискәндереп җибәрде. Шәһәр читенә чыгып барганыбызны күреп, юл һәлакәтедер инде диеп борчылып бара идем, юл буендагы киоск янына килеп туктагач кына җиңел сулап куйдым. Күңелемнән ниндидер куркыныч эшнең шаһиты булам, дип әзерләнеп баргангамы, кибет почмагында канга батып, басып торган кешегә дә мин ничектер бик тыныч карадым. Ул арада полиция дә килеп җитте. Табиб белән полицейский яралы абзыйдан сорау ала: «Ни булды да, ни эшләдең?» Аның ни әйткәнен ишетергә чама юк, бар кешене уздырып кибетче, чыгып китегез, дип кычкыра. Бу кешене күреп, аның күңеле болгана икән. Бераз эчеп алган, туарылган, өстендәге киеме дә бар белән юк арасында, чәче-башы тузгыган бу хатынга караганда, кыйналган исерек абзый күзенә күпкә күркәмрәк күренде. Ә аның белән эш болай булган. Тумышы белән Нурлаттан, Казанда төзелештә эшли. Кичен дусларына килгән, шунда кызып киткән, кунакларның берсе аны кыйнаган, нәрсә беләндер сугып башын нык җәрәхәтләгән. Ике полицейский сугыш чукмарларын эзләп китте, без дүртәү – шофер, ике медицина хезмәткәре, дүртенчесе мин, җәберләнгән кешене алып, хастаханәгә юнәлдек. Рөстәм яраларны юа, бәйли, мин үземә күрә нәтиҗә ясап барам. Бер исерекне алты дәүләт кешесе кайгыртып йөрибез түгелме соң? Ә абзый юл буе хөкүмәтне сүгеп, безнең илдә тәртип, дөреслек булмавын сөйләп барды. Кая дөреслек булсын инде, берәү бер тамагына хуҗа була алмаган да, ничә кешене аякка бастырды. Шулай итеп, исерекне олы хөрмәт белән хастаханәгә илтеп, табиблар кулына тапшырдык. Рөстәмнең әйтүенчә, яралары бик тирән, тегәргә кирәк булачак, бу тиктен суккач, баш мие дә селкенгәндер, диде ул. Бу урында шуны да әйтеп китәргә кирәктер, безнең Казаныбызда бүгенге көндә бер генә дә айныткыч юк, аның соңгысы бер ел элек ябылды. Бу медиклар өчен бер баш бәласе дияргә була. Ярый, башы ярылганын хастаханәгә илттек, ә башкасын кая куярга?

Хәмер темасын кузгатканбыз икән, тагын бер чакыруга туктап китик. Кырык яшендәге хатын аңын югалта, диделәр. Әйтелгән йортның бер башына килеп туктадык, ә анда безгә тиешле фатир юк. Табибның әйтүенчә, бик күпләр үз подъездларын бутыйлар икән. Уйлап карагыз, караңгы төн, тар ишегаллары, анда да ике яклатып машина тезгәннәр, каян кереп, каян чыгарга белмисең, җитмәсә йортларга ни урамы язылмаган, ни йорт номерын күреп булмый. Бер төнлек тәҗрибәмнән, күргәннәремнән чыгып әйтәм, әгәр дә сез яшәгән йортка урам исеме, аның саны язылмаган икән, моны булдыруны үтегез – шунда яшәүчеләр кайгыртса, тиешле кешеләргә кисәтсә икән. Вакытны секундлар белән исәпләгәндә «ашыгыч ярдәм»нең йортлар арасында адашып йөрүе дә бик ихтимал. Бу очракта да ярый әле подъезд ишекләренең берсе ачылып китеп, үсмер кызның башы күренде: «Без чакырдык сезне». Бу гаиләнең дә үз сценарие. Кырык яшендәге ханым үзенә кунакка килеп йөрүче ир белән берничә көн кәефсафа корганнар. Хатынның башы авырта башлагач, кайгыртучан ир аңа үзенең кан басымы күтәрелгәндә эчә торган даруын биргән. Нәтиҗәдә болай да түбән булган кан басымы бөтенләй төшеп беткән, хатын аңсызланып берничә тапкыр егылган. «Әле ярый, аңын гына югалткан, үлеп китәргә дә мөмкин иде», – диде табиб. Авыруның йөрәген яздырдык, кискен үзгәрешләр бар, «Инфаркт булу куркынычы юк түгел», – дип, табиб аны хастаханәгә алып китәргә карар кылды. Бу очракта да сәбәпче аракы, хатын бер җирдә эшләми, ямьсез тормыш алып бара. Без аны киендереп алып чыгып киттек. Ни ана күрше бүлмәнең ишеген ачып кызына: «Китәм», – дип дәшмәде, ни кыз әнисен озатырга чыкмады. Авыруны тиешле документларны тутырып хастаханәдә калдырып, яңадан юлга кузгалдык. Минем исә күз алдыннан үсмер кыз китмәде. Җыештырылмаган, шыксыз әйдә әнисенең чираттагы дусты белән калды мескенкәем! Кем булып, ни күреп үсәсең инде син, бала? Ничек итеп синең үзеңнән дә яхшы ана чыксын...

85тә дә әни кирәк

«Әни! Әни... Күгәрченем минем, нык авыртам, булыш миңа». Юрган ябынып бертуктаусыз такмаклап утыручы бу әбигә бер күз салуга йөрәк меңгә теткәләнә. Менә ул – котылгысыз картлык һәм аның чын йөзе.

Әбиенең йөрәген яздырдык, кан басымын үлчәдек. Бу очракта диагноз бер генә – картлык. Ә иң аянычы, без аңа ярдәм дә итә алмыйбыз. «Сезгә участок табибына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Безнең авыру түгел бу, аңлагыз, без ашыгыч ярдәм күрсәтүчеләр, ә әби әкренләп, җайлап, хәстәрләп карауга, игътибарга мохтаҗ», – дип аңлатырга тырышты табиб әбинең карарга ялланган ханымга. Аның исә үз туксаны туксан: теге көнне килгәннәр иде, мондый укол кададылар, кичә тегесен... Кайберәүләр өчен кискен кирәк булмаганда да «ашыгыч ярдәм» машинасын чакырту берни түгел. Бу төркемгә ялгыз яшәүче үзләренең бу халәтләренә риза булырга теләмичә бәргәләнүче өлкәннәр керә. Кайчакта инде туганнары берәр укол кадап китәрләр дә әби, бабай тынычлап йоклар дигән исәптән яисә нинди дарулар бирик дип сорар өчен дә «ашыгыч ярдәм» машинасын чакырталар. Әлбәттә, һәркем үзенә бердәнбер, ә менә шәһәр буенча алар күпме? «Сәгать бер тулып киткән икән, хәзер берничә өлкән кешегә барырга туры килер, мөгаен», – диде Рөстәм, миңа алдагы маршрутны аңлатып. Әйе, без ул төндә өлкәннәрнең төрлесендә булдык, алар өчен чын кайгыртучанлык күрсәткән балаларны гына күрә алмадык. Бу да күрсәткеч, бүгенгебезнең аяныч диагнозы.

Инде яңа көн дә башланды

Хезмәттәшләремнең тәҗрибәсе күрсәткәнчә, ике тулып киткәндәрәк шалтыратулар кимрәк булырга мөмкин икән. Без исә кичке җидедә үзәктән чыгып киткән идек, иртәнге якта – ике тулып киткәндә үзәккә кайттык. «Ашыгыч ярдәм» машиналары ничек эшли, дип кызыксынучылар да булыр, анысын да аңлатыйм. Бер шалтырату белән барасың да авыруга ярдәм күрсәтәсең, бераз нәтиҗәсен көтеп торасың. Әгәр дә кичекмәстән хастаханәгә алып барырга кирәк икән, авыруны алып китәргә әзерлисең. Бу очракта да табибның бик белеп карар чыгаруы мөһим. Бер хастаханәдән икенчесенә куып йөртмәсеннәр дисәң, тиешлесен, дөрес итеп сайларга кирәк. Анда баргач та яңадан табиблар карый, кирәксезгә алып барган булсаң, авыруны кире борып җибәрүләре дә мөмкин. Безнең белән андый хәлләр булмады. Авыру белән эшне тәмамлагач, үзәккә шалтыратып икенче заявканы кабул итеп аласың. Аларның рөхсәте булса гына, үзәккә кайтасың. Шулай итеп, без дә бер чыгып киткәннән җиде сәгать туктаусыз эшләдек. Бәлки чәй эчәргә өлгерербез, дип хезмәттәшләрем чәйнеккә үрелде, мин исә иртән эшкә барасымны уйлап, «сменамны тапшырырга» булдым. Күргәннәрем дә инде ниндидер нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирәдер. Әлбәттә, төрле очраклар була, мин моны инкарь итмим, гел мактап кына язган димәгез, мин үзем медицина хезмәткәрләренең эшендә бер генә кимчелек тә тапмадым. Авыруларны алып хастаханәләргә баргач та, андагы шәфкать туташларының сабырлыгына хәйран калып карап тордым. Каршыларына кемне генә китермәсеннәр, сыйныфларга бүлмичә кабул итеп алалар, тиешле ярдәмен күрсәтәләр. Шоферны гына күр син, бу шәһәрдә аннан нык ашыккан, кешеләргә ярдәм итәргә тырышучы юктыр кебек тоелды. Мигалка кабызып төнлә буш урамда светофор каршында басып торганда (кагыйдәне бозарга ярамый, штраф салалар), ишегалларында лабиринт кебек тар юлдан машиналарны аралап йөргәндә үзенең күпме нервлары бетә икән аның, ә инде бөкеләр турында әйтеп тә тормыйм.

Ял итәрмен, дип өйгә кайтырга ашыксам да, күзгә йокы кермәде. Медицина өлкәсен өйрәнергә чыккан идем, ә бөтенләй башка нәрсә өчен борчылып кайттым. Урамда, кибеттә без барыбыз да бертөсле кебек, ә менә төн карасын ертып кешеләрнең фатирына кергәч, чынбарлык алдында каласың. Сүз дә юк, әле бер кичтә кешеләрнең бүгенге яшәеше пәрдәсенең бер читен генә ачып карарга өлгергәнмендер. Шулай да, моңысы да миңа бик җитте. Уколлар кадап, системалар куеп, хастаханәләргә салып та дәвалап булмый торган сырхау басып килә икән ләбаса безне. Бу кешеләрнең үзләренә, яшәешләренә битарафлыгы, хайваннарча тормыш алып барулары, эчүчелек. Шуңа бәйле рәвештә, мең төрле мәшәкать, бәла-каза калкып чыга. Ә сәбәбе – иң беренче чиратта рухи фәкыйрьлек.

Скутерда килә, полиссыз да карый

2013 елның 1 гыйнварыннан ашыгыч ярдәм күрсәтү мәҗбүри иминиятләштерү системасыннан бер өлеше булып санала. Ягъни «03» чакыруы белән килгән медицина хезмәткәре авырудан полис сорарга хокуклы һәм тиеш.

«Ашыгыч ярдәм»гә бәйле булган икенче бер яңалык белән дә таныштырып үтик. 1 гыйнвардан Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының «ашыгыч ярдәм»нең килеп җитү вакытын билгели торган приказы гамәлдән чыкты. Полиска бәйсез рәвештә дә ярдәм киләчәк, ә менә ул чыннан да ашыгып килерме – моңысын беркем дә ышандыра алмый. Бу мәсьәләдә яңа нормативлар кайчан кабул ителер – хәзергә билгесез. Бүгенге көндә Казанда «ашыгыч ярдәм» машиналары 13-14 минутта килә дип исәпләнә. Бу мәсьәләдә фикерләрнең төрле булуына шик юк, шулай да аларның бөкеләрдә торуларын һәркайсыбыз белә. 2012 елның декабрь ахырында ТР Хөкүмәте йортында Министрлар Кабинеты белән ТР буенча Эчке эшләр министрлыгы коллегиясенең Татарстан Республикасында «2006-2012 елларда юл хәрәкәте иминлеген арттыру» максатчан федераль программасы үтәлеше нәтиҗәләренә багышланган уртак утырышында Рөстәм Миңнеханов «Казанда транспорт бөкеләре булу сәбәпле, кичектергесез хезмәтләргә, шул исәптән ашыгыч медицина ярдәменә ниндидер чаралар күрергә кирәк, мисалга, җәйге чорда ашыгыч медицина хезмәте табибын кирәк-яраклары белән авыруга тиз арада илтеп җиткерер өчен, мотоцикллар алыргадыр, бәлки, уйлашырбыз», – дип йөкләмә биргән иде. Медикларыбыз скутерларга күчеп утырырмы-юкмы – моңысын вакыт күрсәтер.

Иманлы СҮЗ

Бер дустымда кунакта чәй эчеп, әңгәмә корып утырабыз, сизелми дә намаз вакыты җиткән. Гадәттә, ул вакытта намаз укучыларның башына: «Минем тәһарәтем бармы соң әле?» – дигән уй килеп төшә. Соравым телемнән дә чыккан, күрәсең, дустым бераз сәерсенеп куйды. Ничек инде тәһарәт булу-булмауны онытырга мөмкин?

ПАТШАЛЫК күпме тора?

НӘСЫЙХӘТ

Йосыф ДӘҮЛӘТШИН,
Түбән Кама мәчете имамы

Онытыла шул. Кайвакыт ничек тәһарәт алганыңны, ничек бозганыңны онытасың да, аннан намаз җиткәч, баш катырасың. Әмма, юл фаҗигасендә умыртка сөяген сындырып, ничә еллар аягына баса алмаган дустым өчен ул мәшәкатьләр онытырлык түгел икән: кечесе катетер аша чыга. Шунлыктан ташлар бик тиз җыела, елына икешәр мәртәбә ваттырып чыгартырга туры килә. Ә зурысы тагы да авыррак. Баштан 15-16 сәдәф эчне йомшартучы дару эчәм, аннан соң махсус көйләнгән раскладушкада көтеп ятам... Кайвакыт шулай 5-6 сәгать тә үтеп китә. Шуңа күрә артык ашамаска тырышам.

Кәгазь битләренә язу, мөнбәрләрдән сөйләү өчен уңайсыз булган, әмма тормышта бик тә актуаль мәсьәләгә тукталырга җөрьәт иттем, Раббым ярдәменнән ташламасын. Хаҗәт үтәү мәсьәләсе динебездә зур урын алып тора. Әмма безне борчыган мәсьәләне аңлау өчен, Пәйгамбәребез (с.г.в.) өйрәткән берничә махсус догага тукталып китәсем килә. Сул аягың белән бәдрәфкә кергәндә: иң элек «бисмилләһ»не әйтәсең, аннан соң: «Йа Раббым, мине ир һәм хатын женесеннән булган җен-шайтаннарның явызлыгыннан сакла», – дигән доганы укыйсың. Мондый төр догаларны ана телендә кылсаң да дөрес була. Хаҗәт үтәгән вакытта кеше гаурәт урыннарын ача, шуңа күрә Пәйгамбәребез: «Бисмилләһ»не әйтүең җеннәрнең күзләреннән оят җирләреңне яшерер», – диде. Махсус догасына килгәндә, хаҗәтханәләр шайтаннарның җыела торган урыннары булып тора, шуңа күрә кеше анда Раббысының саклавын сорап керә. Аллаһ теләсә, бу сүзләрне әйтеп керүченең гаурәте каплана һәм ул җеннәрнең зарарыннан имин була. Әмма бәдрәфтән чыккач укый торган доганың хикмәте шәхсән үзем өчен ничә еллар сер булып килде. Пәйгамбәребезнең хатыны Гайшә сөйләвенчә: «Аллаһының илчесе хаҗәтханәдән чыкканда: «Гуфранәкә», – дип әйтә торган булган. Мәгънәсе: «Синең гафу итүеңне үтенәм».

Ни өчен Аллаһының илчесе безне хаҗәт үтәгәннән соң гафу үтенергә чакырды? Моның хикмәте нәрсәдә икән? Шушы сорауга җавап табу нияте белән галимнәр калдырган хәзинәләрне актарырга тотындым. Тырышкан табар, ташка кадак кагар, ди, эзли торгач, сандык төбеннән хикмәте чыкты бит. Тапкан байлыгымны сезгә дә тәкъдим итәм: «Аллаһы биргән киң ризыкларны ашап, алардан үзеңә күп файдалар алып, соңыннан кирәкмәгән өлешеннән җиңеллек белән котыла алу – шундый олуг нигъмәт, кеше моны ахырына кадәр аңлый да, тиешенчә шөкер итеп тә бетерә алмый. Шушы хакыйкатьне аңлап, бәндә үз гаебен танып, Раббысыннан гафу үтенә». (Ибн Галлән хезмәтләреннән.)

Чыннан да, без кайвакыт рәхәтләнеп ашау-эчүләребезнең генә түгел, азап чикмичә хаҗәтеңне үти алуның да олуг бәхет икәнен аңлап бетермибез, тиешенчә шөкер итмибез. Раббым, безне гафу итсен.

Фәрит ВАФИН рәсеме

Пәйгамбәребезнең «Биш әйбердән элек биш нәрсәнең кыйммәтен белегез, – дип башланучы хәдисендә болай дип боерыла: үлем мизгеле килеп җиткәнче тормышның, хасталык килгәнче сәламәтлекнең, фәкыйрьлеккә дучар булганчы мөлкәтнең, картайганчы яшьлекнең, мәшгуль булганчы ия булган буш вакытның кыйммәтен бел».

786-809 елларда Багдад хәлифе булган Һарун әр-Рашид бервакыт, бик каты сусагач, хезмәтчесеннән касә белән су китерүен сорый. Элекке заманнарда патшалар үзләре тирәсенә хикмәт ияләрен җыярга тырышканнар, тегеләре һәрвакыт хуҗаларына хикмәтле киңәшләр биреп торганнар. Һарунның хезмәтчесе бик зирәк була. Патша кулындагы суны эчәр алдыннан, ул аңа бер сорау да биреп өлгерә: «Әмирем, әгәр бик каты сусап иза чиксәң, шушы бер касә су өчен күпме байлыгыңны бирер идең?» Шулвакыт патша бераз уйга кала. Чыннан да, сусыз чүл уртасында калсаң, бу өч йотым суның бәһасе никадәр булыр иде? Патша: «Мөгаен, ярты патшалыгымны бирер идем», – дип җавап кайтара. Сусаган хуҗа ләззәт белән суны эчеп куя, хезмәтче озак көттерми, янә сорау бирергә батырчылык итә: «Патшам, әгәр шушы су, карыныңа үтеп, чыкмыйча азапласа, аннан котылу өчен күпме бирер идең?» Бу сораудан соң хәлиф тәмам уйга төшә. Тормышта рәхәтләнеп салкын сулар эчү генә нигъмәт түгел икән шул. «Ярты патшалыгымны бирер идем», – дия. Шулвакыт хезмәтчесе аңа: «Әй, хуҗам. Синең бөтен патшалыгың, бөтен байлыгың бер касә бәвелгә дә тормый икән», – дип, әмирнең күңелләрен тетрәндерерлек сүзләр әйтеп куя.

Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Кешеләр ике төрле нигъмәтнең кадерен белмәсләр: сәламәтлек һәм вакыт», – дигән. Чыннан да, күп вакытта, без һавадагы торналарны эзләп, кулыбыздагы песнәкләрне күрми яшибез. Күктән иңгән күпме нигъмәтләрнең кыйммәтен аңламыйбыз. Бәлки, аларны тир түгеп, михнәтсез алганга кадерләрен белмибездер. 70 яшьлек бер бабайны хастаханәгә салганнар. Бабай кече йомышын үти алмый икән. Табиблар аны операциягә әзерли башлаганнар. Шөкер, операция уңышлы үткән. Бабайның өенә кайтыр көне килеп җиткән. Хастаханә җитәкчелеге бабайның кулына дәваның бәясе язылган кәгазь тоттырган. Кәгазьдәге саннарны күргәч, аның күзләреннән яшь чыккан. Бабайны кызганып, табиблар аны юатырга тотынган: «Бабакай, син олы кеше булгач, без бераз бәясен төшерербез инде». Ул табибларга караган да, елмаеп: «Мин бит бәянең күплеген күреп еламыйм. Раббым миңа 70 ел йомышымны үтәргә насыйп итте, бер мәртәбә дә кулыма мондый кәгазь тоттырмады, мин шуңа елыйм», – дигән.

Шулай шул, кайвакыт кеше машинам яңа дип тәмәкене урамга чыгып тарта. Ничек 600 меңлек машинаңа тәмәке исе сеңдерәсең инде? Әле 3 ел буе кредитын түлисе. Ә саулык күктән төшкән, бушка килгән. Ләкин машинаң тузса, аны яңартырга да була, менә саулыгыңны яңарта башласаң, акчаң гына җитмәс. Әгәр саулык дигәне базарларда сатылса, авырудан иза чигүче байлар аның өчен бер малларын да кызганмаслар иде. Акчалары җитмәсә, банктан кредит алырлар иде, ләкин, күп нигъмәтләр акчага сатылмый икән. Аларның бары тик кадерен белергә, бүләк итүчесенә рәхмәтле булырга кирәк.

Кайвакыт кеше машинам яңа дип тәмәкене урамга чыгып тарта. Ничек 600 меңлек машинаңа тәмәке исе сеңдерәсең инде? Әле 3 ел буе кредитын түлисе. Ә саулык күктән төшкән, бушка килгән. Ләкин машинаң тузса, аны яңартырга да була, менә саулыгыңны яңарта башласаң, акчаң гына җитмәс

Пәйгамбәребезне зурладылар

БӘЙРӘМНӘН СОҢ

Бу атнада Камал театры бинасында ТР Мөселманнары диния нәзарәте Мәүлид бәйрәме уздырды. Узган елгы чарага караганда, быелгы бәйрәм оештыру ягыннан күпкә дәрәҗәлерәк иде.

Шуңа да карамастан, узган елдагыдан аермалы буларак, әлеге бәйрәмдә ни Президентыбыз, ни мөфтиебез күренмәде. Аның каравы, бәйрәмдә Татарстан мөселманнарын котларга Мәскәү, үзәк төбәк һәм Чуаштан мөфтие Әлбир хәзрәт Крганов, Ханты-Манси автоном округы мөфтие Таһир хәзрәт Саматов, Дагыстан мөфтие урынбасары Мөхәммәд Мөхәммәдев кебек дин өлкәсендәге рәсми затлар килгән иде. Үзебезнең Диния нәзарәтеннән Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Габдулла хәзрәт Әдһәмов һ.б. казый-имамнарыбыз чыгыш ясады. Хәзрәтләребез тамашачыларга Расүлебез турында җитди вәгазьләр, күркәм нәсыйхәтләр ирештерде. Кичә дәвамында Пәйгамбәребезнең төп коралы – Коръән һәм шәхси үрнәк булуы ассызыкланды. Гайшә анабыз: «Пәйгамбәребезнең холкы Коръән иде», – дип әйтә торган булган.

Мәскәү, үзәк төбәк һәм Чуаштан мөфтие Әлбир Крганов, үз чыгышында узган елның җәйаенда булган вакыйгаларны искә төшереп: «Кайберәүләрнең үзләрен Аллаһыдан да өстен куеп, дин белән уйнаулары Пәйгамбәребезне дә, Аллаһының фәрештәләрен дә, безне дә, әлбәттә, рәнҗетә. Хәзер илебездә сигез меңләп мәчет, уку йортлары. Шуларга шөкер итмәсәк, безгә нәрсә булыр?!» – диде. Кяферләр белән сугышкан чакта иман китереп өлгергән, әмма шуңа да карамастан башы чабылган бер бәндә өчен Пәйгамбәребез (с.г.в.)нең үзенә урын таба алмыйча: «Каян белдең син аның күңелен? Ни хакың бар иде мөселманны үтерергә?» – дигән хәдисен үрнәк итеп китерде ул.

Коръәни-Кәримне укудан башланган дини бәйрәмдә салаватлар әйтелде, мөнәҗәтләр укылды, нашидләр башкарылды. Татарстанның күренекле сәнгатькәрләре Зөһрә Сәхабиева, Флюра Сөләйманова, Миңгол Галиев, Луара Шакирҗаннар репертуарларындагы дини әсәрләрен башкарды. Әнкарадан Фатых Хаҗә һәм Дагыстаннан «Рисалә» ансамбленең чыгышлары исә Казан тамашачысына горур милли рухның нинди булуын күрсәтте.

Февральдә намаз вакытлары

	Иртәнге намаз	Кояш чыга	Өйлә намазы	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
1	07:07	08:37	13:02	15:25	17:17	18:47
2	07:05	08:35	13:02	15:27	17:19	18:49
3	07:03	08:33	13:02	15:29	17:21	18:51
4	07:01	08:31	13:02	15:31	17:24	18:54
5	06:59	08:29	13:02	15:33	17:26	18:56
6	06:57	08:27	13:02	15:35	17:28	18:58
7	06:55	08:25	13:02	15:37	17:30	19:00
8	06:53	08:23	13:02	15:39	17:32	19:02
9	06:51	08:21	13:02	15:41	17:34	19:04
10	06:49	08:19	13:02	15:43	17:37	19:07
11	06:46	08:16	13:02	15:45	17:39	19:09

Бергәләп тотынсак...

Аллаһыга тапшырып, Арча шәһәренең Шәрык өлешендә 2012 елның 25 октябрендә (Корбан гаете көнне) мәчеткә нигез салынды. Мәчетнең һәм мәдрәсәнең гомуми мәйданы 2500 кв. м булыр дип планлаштырыла. Бүгенге көндә мәчетнең беренче катының кирпеч белән төзү эше эшләнде. Алда мәчетнең икенче һәм өченче катын күтәрү тора. Гомер-гомергә мәчетләр бар халык һәм оешма җитәкчеләре ярдәме һәм көче белән төзелгән. Бу изге бина төзелешендә катнашырга теләгән гражданнар һәм оешма җитәкчеләре өчен аның исәп-хисап счетын тәкъдим итәбез.

Местная мусульманская религиозная организация приход «ВОСТОЧНЫЙ»
ИНН 1609009509
КПП 160901001 р/счет №40703810662060100038
БИК 049205603 Кор. счет № 30101810600000000603
Высокогорское отделение № 4655 ОАО Сбербанка России ст. Высокая Гора

Ярдәм итәргә теләүчеләр шушы телефон номерына да акча сала алалар: **+79600526026**.

Имам Ильяс Дулкарнай

Бердыев Фергюсоннан ким түгел

Узган ел ахырында «Рубин»ның баш остазы Корбан Бердыевка клубта вице-президентлык вазифасыннан баш тартырга туры килсә дә, тренерлык кәнәфиен саклап кала алды. Шул рәвешле, ул заман футболының «озын гомерле» тренерлар сәхифәсендәге урынын тагын да ныгытты. Быелның июнь аенда Корбан Беки улының «Рубин»ны җитәкли башлавына 12 ел тула. Тренерларның еш алмашынуы гадәти күренешкә әйләнгән Россия футболы өчен моны хәтта гайре табигый хәл дияргә була.

Казан клубына килүенең икенче елында ук Бердыев «Рубин»ны Премьер-лигага чыгаруга ирешә. Дебют сезонында чемпионатның бронза медальләрен яулаган «Рубин» берничә ел эчендә илнең топ-командалары арасына керде. 2007, 2008 елларда рәттән ике тапкыр ил чемпионатында җиңеп, лидерлык позицияләрен ныгытты. Корбан Бердыев һәм «Рубин»ны чын мәгънәсендә дөнья аренасында таныткан вакыйга 2009 елда «Камп Ноу»да «Барселона»ны җиңү булды. Бердыевны юкка гына әлеге тарихи җиңүнең баш конструкторы дип атамыйлардыр. Озак еллар дәвамында клубта иң дәрәҗәле, хәтта кагылгысыз шәхескә әйләнгән Бердыев өстендә узган ел ахырында болытлар куерып алса да, остаз Казан клубы белән хезмәттәшлеген саклап кала алды.

Дөнья футболы практикасында бер клубны дистә елдан артык җитәкләгән футбол тренерлары Бердыев белән генә чикләнми, билгеле. Араларында ике дистә еллап, аннан да озаграк остазлык иткәннәре бар.

Заманыбызның иң уңышлы тренерларының берсе, Франция остазы **Арсен Венгер** Лондон «Арсенал»ында инде 1996 елдан бирле. Шушы вакыт эчендә ул Англия премьер-лигасы легендасына әйләнде. Венгер әлеге команда белән иң озак эшләүче тренер буларак рекорд та куйды. «Арсенал»ны өч тапкыр ил чемпионы иткән остаз XXI гасыр башында дөньяның иң яхшы тренеры дип табылды. Тик менә соңгы елларда

Корбан Бердыев

Алекс Фергюсон


Арсен Венгер

команданың теге яки бу турнирда уңышка ирешә алганы юк. «Арсенал» Венгер җитәкчелегендә ахыргы титулын җиде ел ярым элек яулаган булган.

Англия чемпионаты лидерларының берсе «Манчестер Юнайтед»ны исә **Алекс Фергюсон**нан башка күзаллап та булмый. Әлеге клубны 1986 елдан бирле җитәкләүче остаз Британия футболында иң зур титуллы тренер дип санала. Сэр Фергюсон дөнья футболы тарихындагы иң бөек тренерларның берсе.

«Манчестер Юнайтед»та, гомумән, тренерларны перчатка урынына алмаштырып торуны файдалы гамәл дип санамыйлар. Соңгы 67 елда клубны бары 8 тренер җитәкләве шуның ачык дәлиле. Чагыштыру өчен, Мәскәү «Спартак»ында соңгы дистә елда шулкадәр үк тренер алмашынган.

Фергюсонга кадәр «МЮ»ны җитәкләгән Мэтт Басби 24 ел үз вазифасын башкарган булса, сэр Алекс аны да уздырды. 26 ел остазлык итү дәверендә ул команда белән 12 тапкыр Англия чемпионатында җинде, ике тапкыр Чемпионнар лигасын буйсындырды.

Төньяк Ирландия чемпионаты тарихында иң уңышлы тренерларның берсе булып саналган **Ронни Макфолл** да «Портадаун»ны чирек гасырдан артык җитәкли. Шул вакыт эчендә ул биш тапкыр илнең иң яхшы тренеры булып танила, клуб белән төрле дәрәҗәдәге 20 трофей яулауга ирешә. Дөрес, соңгы елларда «Портадаун» зур уңышлары белән сөендерә алмый. Инде менә 10 ел команданың чемпионлык исемен кайтару буенча көрәше нәтиҗәсез тәмамлана. Шуңа да карамастан, Макфолл үз постында кала бирә.

Бер болганмый су да тынмый

«Рубин»да булган проблемалар хәл ителде. Команданың төп бурычы – ниндидер җәнҗалларга әләгү түгел, ә спортта казанышларга ирешү. Алга таба иҗади эш алып барылыр дип ышанам». Күптән түгел республиканың әйдәп баручы ММЧ җитәкчеләре белән очрашуда, «Рубин»га бәйле вазгыятьне шәрехләп, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов шулай дип белдергән иде.

Соңгы араларда Казан клубыннан килеп ирешкән хәбәрләр, чыннан да, «Рубин»да хәлләрнең торыклана башлавына ишарәли. Бу атнада клубның вице-президенты Камил Исхаковның үз вазифасына керешүе моңа тагын бер дәлил. Исхаковка әлеге пост узган елның соңгы көннәрендә «Рубин»ның Попечительләр советы утырышында тәкъдим ителгән иде. Беркадәр уйлаганнан соң, ул кайчандыр үз канаты астында булган клубта яңа вазифа башкарырга ризалыгын бирде.

«Рубин»нан качып китеп, агентлык түләүләре белән бәйле шау-шу тудырган төрек уенчысы Гекхан Тереның да бу көннәрдә Испаниядә җыеннарда булган командага кушылуы турындагы хәбәрләр килеп ирешә.

Кирәк икән, «КамАЗ-Мастер» ил данын футбол кырында да яклаячак

Ике дус сөйләшә:

– Безнең «КамАЗ»лар тагын «Дакар» раллиенда җиңде бит. Син ишеттеңме әле, аларны футбол буенча дөнья чемпионатына Россия данын якларга җибәрмәкчеләр ди.

* * *

Футбол стадионы. Алмания – Согуд Гарәбстаны матчының 90 нчы минуты. Исәп алманлылар файдасына – 8:0. Гарәп шәехе янәшәсендә кәефләнеп утыручы бюргерның колагына пышылдый:

– Әйтегез әле, сәгать ярым элек Алманиядә бензин күпме тора иде?

* * *

– Россиянең футбол буенча җыелма командасы белән Канаданың хоккей командасын нәрсә берләштерә, беләсеңме?

– Алар икесе дә футбол уйный белми.

* * *

Футбол клубы президенты:

– Бүгеннән теорияне өйрәнүне туктатабыз.

– Нигә?

– Футболчылар тупка тибәр алдыннан кирәгеннән артык озак уйлый башлады.

* * *

Парашютта сикергәннән соң, курсант инструктор янына килә:

– Ике тапкыр сикердем, язып куегыз әле.

– Нәрсә сөйлисең, бу бит әле беренче генә сикерүегез иде.

– Бу беренчесе һәм соңгысы булды.

Вәгъдәләшкән хоккейчы егет озак кына алка кертә алмады



Хоккейчы Александр Овечкин 2013 елның тормышында зур үзгәрешләр елы буласын яңа елның беренче көнендә үк хәбәр итеп куйган иде. НХЛ «йолдыз»ы танылган теннисчы Мария Кириленко белән вәгъдәләшүләрен Twitterында хәбәр итте. Тик бу шатлыклы вакыйганы голлары белән генә озак билгеләп үтә алмады Ови. Овечкин капитанлык иткән «Вашитгтон» локауттан соңгы старт матчларын уңышсыз уздырды. Бер-бер артлы җиңелүләр кабатланып торды. Моның төп сәбәбе тренерларның Овечкинны элекке позициясеннән һөҗүмнең уң флангына күчерүендә булган икән. Аны элекке позициясенә күчерү белән, хоккейчы беренче җиңүен дә яулады.

Сәхифәне Айгөл **ФӘХРЕТДИНОВА** әзерләде

Максуд ЮЛДАШЕВ:

«МИН ЭКОЛОГ БУЛЫРГА ТИЕШЛЕ КЕШЕ»

«Бәрхет баритон». Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Венера Ганиева аның тавышына шундый бәя бирә. Максуд Юлдашевның Казан мәдәният һәм сәнгать университетындагы вокал бүлегендә укуы тәмам булуга, М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрына эшкә кодалаучы да нәкъ Венера Әхәтовна. «Татар моңы-2011»нең җиңүчесе Максудның теленнән шуңа да остазы төшми: «Хәзер дә кирәк вакытта мин Венера Әхәтовнага барып вокал дәресләре алам. Укучылары белән шул дәрәҗәдә якын эшләүче тагын берәр җырчы бармы икән ул? Ул яктан Ганиева укучылары өчен бәхет чиктән ашкан, ул – гомерлек дус булып калырлык остаз».

ЙОЛДЫЗЛЫ ЮЛ

Гөлнара ЖӘЛИЛОВА

Әлки районы Базарлы Матак авылына Ургенч шәһәреннән кайтып төпләнгән Юлдашевлар гаиләсендә биш бала үскән. Әнисе – укытучы, әтисе машина йөртүче булып эшләсә дә, җыр-моң дигәндә бик тә талымлы алар. Төпчекләре –1984 елда туган Максуд та шул исәптән. Максуд белән беренче тапкыр «Татар моңы» телевизион яшь башкаручылар конкурсында җиңгәч танышкан идек. Опера һәм балет театрында эшләүче артистның җиңмәве гаҗәп булыр иде инде. Әмма миңа барыннан да бигрәк Максудның тәрбияле, эчке культуралы булуы ошады. Шуңа да аның театрдан китеп, «ялгыз йөзү»гә күчүен белгәч, аптырашта да калдым. Ник?

– М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында мин биш ел эшләдем, – дип башлый сүзен Максуд. – Анда эш кызыклы иде. Гастрольләр белән бөтен дөньяны диярлек күрдек – Голландия, Испания, Португалия, Бельгия, Германиядә әллә ничә тапкыр... Әмма миңа нидер җитми башлады. Поп-музыка, рок-н-ролл, тәсләр уйнавы, шоу димме? Мин театрда эшләгән биш елыма бик рәхмәтле, ул зур мәктәп, зур сынау булды. Әмма үземә башка тармак, башка дөнья кирәген белгәч, китми калу дөрес булмас иде.

– Ә син хәзер кайда соң?

– Мин башта ялгызак кына аппаратура белән эшләп, үзем җырлар яздырып йөрдем. Менә күптән түгел генә «Бродвей» төркеме белән эшли башладым. Аның солисты. Төрле телдәге җырлар тәкъдим итәбез. Миңа кадәр әлеге төркемнең солисты «Голос» телевизион конкурсында беренче урынны яулаган Динә Гарипова иде. Ул Мәскәүгә киткәч, мине чакырдылар.

– Син дә берәр конкурста катнашып, Казаннан китеп барырга күп сорамассың әле...

– Юк, минем иң курыккан конкурслар бугай. «Татар моңы»ндагы чыгышыма да яхшы бәя бирә алмыйм. Белмим, ул нинди халәттер инде – мин телевизион концертларда рәхәтләнеп эшли алам, ә конкурста жюри каршысына чыгам икән, шундук коелып төшәм, каушыйм, тавышым да юкка чыгарга мөмкин.

– Кечкенәдән сәхнә дип янган кеше түгел икәнсең алайса?

– Юк, җырлап үссәм дә, мин киләчәгемне җыр белән бәйләрмен дип уйламаган идем. Уртанчы апам артыннан Ростовка китеп, эколог булырмын, дип йөрдем. Миңа ул һөнәр бик ошый. Ә язмыш табигый талантка басым ясарга булды.

– Иҗат дигәндә, үзеңә кирәкле юнәлешне сайладыңмы әле?

– Юк. Эзләнүдә дисәм, дөресрәк булыр. Җырлар яздыра башлагач та, шуңа килеп төртеләм. Миңа шәхсән Григорий Лепс иҗаты ошый. Аның кайбер ноталарны алу мөмкинлеге, иҗади бунты җәлеп итә мине. «Бродвей» белән эшли башлагач та, мин тавыш мөмкинлекләрем белән эшләүне яңарттым. Бу нисбәттән кабат Венера Ганиева белән вокал дәресләрен гамәлдән төшереп калдырган юк.

– Инде өч дистә яшькә якынлашкан егеттән йөрәк хәлләре турында да беләсе килә.

– Минем өстенлек – эчке матур дөнья, гадилек, татар хатын-кызларына хас тыйнаклык. Язмыш миңа шундый зур мәхәббәт бүләк итәр дип уйлыйм.

– Картайган Максуд Юлдашев нинди булыр дип күзаллыйсың?

– Картайган?! Мин һәрвакыт яшь калырмын дип уйлыйм. Максуд Юлдашев, зур зал, аншлаг, шәп, креатив концерт-шоу, төрле тәсләр уйнавы...

– Филипп Киркоров шоуын да уздырырсыңмы икән?

– Алла боерса! Иҗатта яңа дулкын буласым, бию шоулар, киң ракурслы иҗат юлы телисем килә үземә. Моның янәшәсенә шәхси бәхет, ким дигәндә, өч балалы гаилә дә булырга тиеш...

ОКЕАН АРТЫ

Шэрон Стоун — Киркоров сөяркәсе?

54 яшьлек танылган Голливуд актрисасы **Шэрон Стоун** комедия жанрында фильмда төшәргә ризалык биргән. «Любовь в большом городе» комедиясен төшерүчеләр өчен ул, әлбәттә, очсызлы табыш түгел. Актриса үзенең роле өчен 400 мең доллар күләмендә гонорар алачак. Шэрон Стоунны фильмда төшәргә чакыру поп-король **Филипп Киркоров** идеясе. Фильмда Святой Валентин булып уйнаучы җырчының хыялы чынга ашарга тора икән. Ул инде күптән Стоун белән бер картинада төшәргә теләгән. Филипп Киркоровның гонорары турында әлегә билгеле түгел икән. Фильмны төшерү Лос-Вегаста бара. Шэрон ничектер, Филя шат ди...

Питт — Джолиның җиденчесе

Әйе шул, танылган актерлар, күп балалы гаилә тагын ишәергә җыена. Чит ил таблоидлары язуы буенча, **Бред Питт** һәм **Анджелина Джоли** гаиләләрендә җиденче бала туарга тора. Анджелина көмәнлелегенең дүртенче аенда икән. Баланың малай икәне дә билгеле, аңа әти-әни Джон дип исем дә сайлап куйган. Әлегә Анджелина токсикоз белән интегә һәм өлкән балаларын энекәшләре туасына рухи яктан әзерли икән.

Ике көнлек балага — кроссовка

22 гыйнварда ир бала тапкан җырчы **Шакира** инде бала тудыру йортыннан чыккан. Шөкер, ана да, бала да үзен яхшы хис итә ди. Футболчы **Жерар Пике** сөйгәне һәм улы Милан Пике Мебарака белән мәш килеп ята инде хәзер. Әти кеше иң беренче эше итеп ике көнлек улына кроссовкалар кидереп, фотога төшерергә дә өлгергән. Аларны интернеттан карап хозурланып була. Ул нәни аякларга ничек кроссовка яратканнардыр, анысы караңгы, әмма дә ләкин «Барселона» футбол клубының яңа әгъзасы Милан өчен башкача килешмәс тә иде. Ике көнлек дип инде, шәп футболчының яшенә карап тормыйлар...

Сәхифәне **Гөлнара ЖӘЛИЛОВА** әзерләде

Алексей Воробьев

Жанна Фриске белән Дмитрий Шепелев

Сергей Филин

МӘСКӘҮЛӘРДӘН СӘЛАМ

Алексей Воробьев параличланган

Узган атнада Лос-Анджелеста авариягә очрап, авыр хәлгә тарыган Россия җырчысы **Алексей Воробьев** турында бәхәсләр тынып тормый хәзер. Кемдер җырчының авыр хәленә кереп, өмет өстәргә тырышса, кемнәрдер әлеге хәлне пиар адым, чынлыкта бернинди авария дә булмаган, Алексейнең реанимациягә эләгүе дә ялган, дип бара. Моңа җирлек булып Лос-Анджелес полиция хезмәтендә рус кешесе катнашында бернинди дә авария теркәлмәве санала. Соңгы мәгълүматларның берсе – җырчының продюсеры **Катерина фон Гечмен-Вальдек** әйтүе буенча, бу журналистларның уйдырмасы гына. Алексей авариягә очраган, хәзер аны реанимациядән неврология бүлегенә күчергәннәр. Әлегә хәле уртача. Воробьевның баш миенә зыян килгән, хәтере юк, параличланган икән. Аңа хәзер энә белән дәвалау курслары уздырырга җыеналар.

Жанна малай табачак

Майамига баласы туганчы ял итәргә киткән **Жанна Фриске**ның сер пәрдәсе ачылды. Аларның телевидение алып баручысы сөйгәне **Дмитрий Шепелев** белән туачак уртак балаларының җенесе билгеле булды. Жанна малай табачак! Йолдызлы гаилә танылган җырчы Кристина Орбакайте бәбиләгән клиникага туктаган икән. Жанна Майамида көз айларына кадәр булырга җыена. Карлы-салкын Мәскәүдә бәби табып үстерергә ятарга тагын, булмаганны...

«Күзләрем авырта»

Зур театрның сәнгать җитәкчесе **Сергей Филин** әлегә хастаханәдә дәвалануын дәвам итә. Исегезгә төшереп үтәбез, билгесез кеше аның йөзенә кислота сибеп, тән тиресе пешү, күзләренә зыян килү белән Филин хастаханәгә озатылган иде. Үзенең хәле турында ул түбәндәгене бәян итә: «Иң күбе күзләр борчый. Мине күпләр: «Филин, нык бул, син бит молодец!» – дип тынычландыра. Иң мөһиме – тизрәк аякка басу һәм эшкә чыгу. Минем гаиләм һәм балаларым бар бит».

Фикер КЫРЫ

Кагыйдәләрне бозар өчен уйлап чыгаралар, диләр. Җир йөзендә үз гомерендә бер тапкыр гына булса да канун (закон) бозмаган кеше юктыр ул. Сабыйларны, бала-чаганы исәпкә алмаганда, әлбәттә. Россиягә килгәндә исә, безнең илдә кануннар белән тулаем исәпләшеп яшәү бөтенләй мөмкин түгел, минемчә.

ЗАКОННАРЫБЫЗ «ямауга» мохтаҗ

Айнур ГАЛИМОВ

Әмма канунның тыюларын, кисәтүләрен бозу күңелсез нәтиҗәләргә китереп җиткерүе бик ихтимал. Бу шуклык түгел, аның өчен берничә минут почмакта басып торып кына котылып булмас. Һәрхәлдә, намуслы гражданнар канунны санга сукмау адымына чарасызлыктан, бик кирәк булган очракта гына баралар. Ә бу эш белән артык мавыгып киткән затларның тәгәрмәчләренә хокук саклау органнарының иртәме-соңмы юан таяк тыгачаклары көн кебек ачык.

Берәр кешегә үз ниятен чынга ашыруга канун тыюы комачаулый, ди. Кеше максатына ирешү юлында канунны атлап кына да үтәр иде, тик, алай эшләгәндә, ачыктан-ачык җинаять кылганын ул яхшы аңлый. Нишләргә? Бер караганда, тупикка терәлде төсле, кешегә хыялдары белән хушлашу хәерлерәк. Юк, мәсьәләне бер якка да зыян китермәслек итеп чишүнең бер юлы бар. Бу – кануннардагы «тишекләр».

Кануннарны бозмаска тырышып яшәүчеләр белән аларга төкереп бирер көн күрүчеләр арасына кануннарны үз файдаларына авыштыра белүче хәйләкәр затлар кереп кысыла. Ул канунда язылган тыюларны да бозмый кебек, шул «тишекләр» ярдәме белән күп очракта хаксыз, әхлаксыз булган ниятен дә чынга ашыра.

Данлыклы өч «М»

Россия тарихында канундагы ямауга мохтаҗ урыннан файдаланып, чынга ашырылган иң күләмле афера данлыклы «МММ» системасыдыр, мөгаен. Эш шунда: безнең канунчылыкта финанс пирамидалары төзүгә билгеле тыю юк. Тыелмаган икән, димәк, рөхсәт ителгән, дип фикер йөртеп, Мавроди үзенең беренче шундый пирамидасын 1994 елның февралендә төзегән иде. Шул ук елның августында «МММ» хөкүмәт тарафыннан җимерелде, әмма 7 айлык эшчәнлеге дәвамында да Мавроди 10-15 миллион кешене кәкре каенга терәтергә өлгерде, 50ләп кеше хәтта үз-үзләренә кул да салды. Кыңгыр эшчәнлеге өчен төрмәдә дә утырып чыккан Мавроди 2011 елда үзенең яңа финанс пирамидасын булдырды, анысының эшчәнлеге интернет челтәрендә җәелдерелде. «МММ-2011» җимерелгәч, хәзерге көнгә кадәр нәтиҗәле (Мавроди өчен) эшләп килүче «МММ-2012» төзелде. Ул системага 35 миллионга якын кеше теркәлгән, бу Россиянең дүрттән бер халкына тиң. Бердәнбер сорау туа: күпме халыкны төп башына утыртып, берничә каршылыксыз эшләп килүче әлеге финанс пирамидасын һәм аңа охшаш туып торучы башкаларын нигә канун тарафыннан бөтенләйгә тыеп куймыйлар икән? Күпчелек дәүләтләрдә финанс пирамидаларын инде күптән авызлыклап бетерделәр, ә бер үк тырмага инде ничәмә тапкыр баскан Россиянең һаман да бер канун кабул итәргә кулы җитми. Моңа әлеге дә баягы бер үк җавап – Тютчев ике гасыр ярым элек үк (1866 елда) язган шигырь сүзләре: «Россияне акыл белән аңлап булмый».

> *Швейцариядә бер бар хуҗасы, җәмәгать урыннарында һәм бина эчендә тәмәке тартуны тыючы канун кертелгәч, хәйләгә барган. Бар кунаклары уңайсызлык кичермәсеннәр өчен, ул өстәлләр янындагы диварларга ике кул һәм башны тыгып була алырлык тишемнәр эшләп куйган. Кеше үзе бина эчендә, әмма урамда тарта бит!*

«Тишек» ничек коралга әверелә

Кануннардагы «тишекләр»не үз файдаларына авыштыруның тагын бер киң таралган мисалы уен автоматларына бәйле. Халыкның шул «беркуллы бандит»ларга бәйлелеге наркоманиягә һәм эчүчелеккә тиң чиргә әверелеп баруын күреп, 2009 елның 1 июленнән хөкүмәт Россиядә уен бизнесын тыйган канунны гамәлгә керткән иде. Канун кабул ителәсен алдан ишетеп, кайбер уен бизнесы белән шөгыльләнүче эшкуарлар баштан ук уңайлы хәстәрен күрде. Хокук саклау органнары уен автоматлары салонына аны ябарга дип киләләр, тик, баксалар, ул урында канунга каршы килердәй бернинди оешма да юк икән инде. Бинаның ишеге өстендә дә «Интернет-кафе» яки «Лотереялар уйнату» дигән язу балкып тора, фирманың документлары да тәртиптә. Шушы «коймадагы ярыктан» файдаланып, шәһәрләрдә, яңгырдан соң баш төрткән гөмбәләрдәй, бер-бер артлы интернет салоннары калкып чыга башлаган иде. Хәзер аларның да кырыс контроль астына алдылар алуын, әмма артык оста эшкуарлар бу керемле бизнесларын дәвам иттерү өчен тагын да хәйләле ысуллар уйлап чыгара. Шәһәрләрдә, шул исәптән Казанда да уен автоматлары салоннары, сауналар, бильярд клублары һ.б. оешмалар маскалары артына яшеренеп, рәхәтләнеп эшли бирә. Казанда йөзләгән шундый оешма бар, диләр.

Кануннардагы төзексезлектән бик уңайлы гына файдаланып, көн күреп ятучылар рәтенә акча күчерү терминаллары тотучы оешмалар, түләү агентлары, электрон янчык операторлары керә. Мондый эшчәнлек төрләре белән шөгыльләнүче оешмалар акча күчерүдә арадашчы ролен уйнап, ул операцияләрне чынга ашырганда, аз түгел күләмдә комиссия тотып калалар, комиссиянең күләмен дә үзләре билгелиләр. Бу бик үк дөрес эшчәнлек түгел, әмма канунда аны тыючы бер пункт та юк. Салым Кодексы кредитны оешмаларга (Үзәк Банк рөхсәте белән банк операцияләрен чынга ашыручы оешмалар) гына комиссияләр тотып калуны тыя, ә терминал, электрон янчык, башка түләү системалары ул оешмалар рәтенә керми. Бер яктан караганда, кредитлы оешмаларның чыгымнары да күбрәк, аларга таләпләр дә кырысрак, әмма нишлисең, «юк» белән судлашып йөреп булмый бит.

Иң күп «тишекләр» исә юл йөрү кагыйдәләрендәдер, мөгаен. Беренчедән, алар еш үзгәреп тора, икенчедән, күп машина сөючеләр хәзер үз хокукларын юл полициясе хезмәткәренә карагандә да яхшырак беләләр. Юллардагы бөкеләр белән көрәш, юл хәрәкәтен машина йөртүчеләр өчен дә, җәяүлеләр өчен дә куркынычсызрак итәргә тырышу максатында кертелеп торган төзәтмәләр бер-берсенә каршылыклы булган очраклар да байтак. Нәтиҗәдә юл йөрү кагыйдәләре буенча хәрәкәт итүче ике машина да һәлакәт хасил итәргә мөмкиннәр.

Көлке дә, гөнаһ та

Кануннардагы «тишекләр» кайчагында кызыклы хәлләр дә китереп чыгара. Мисалга шушы очракны китерергә була. 2011 елның июлендә сыраны кайсы урыннарда сатарга яраганлыгын билгеләүче канун гамәлдән чыгып, аның яңасы 2012 елның июлендә генә кабул ителергә тиеш иде. Юристлар шунда ук чаң суга башладылар – бу хәл сыраны теләсә кайсы җирдә сатарга яраганлыгын аңлата бит! Хет мәктәп территориясендә сат, хет маршрут автобусында. Ахыр чиктә, бу ялгышның ашыкканлык белән китүен аңлатып, барысын да җайга салдылар.

Менә тагын бер кызыклы хәл. Алдан ук кисәтеп куйыйм: аның дөреслеге турында үз өстемә бернинди дә җаваплылык алмыйм, чөнки кешедән ишеткәнне генә бәян итәм. Эш шунда: безнең кануннарда документ кәгазь битенә тутырылырга тиеш дигән билгеле кисәтү юк икән. Бер эшмәкәр бу хәлдән бик оста файдаланган. Банк белән ниндидер аңлашылмаучанлык килеп чыгып, бәхәс тугач, банк хезмәткәрләре моңа: «Ризасызлыгыгызны язып китерегез, аны 60 көн эчендә тикшерербез дә баш тартырбыз», – дип белдергәннәр. Шулай әйткәндә, алар эшмәкәрнең кабер ташлары җитештерүче икәнен исәпкә алмаганнар. Берничә көннән рәнҗүле эшкуар, банкның ишегенә үк терәтеп, 12 тонналы таш китертеп куйган, ә ташка аның ризасызлыгы, хәтта җавап адресы, реквизитлары чокып язылган, кулы да куелган булган. Эш урыннарына тәрәзә аша керергә мәҗбүр булган банк хезмәткәрләре полиция чакыртканнар, тик хокук саклаучылар җинаять составы булмавын теркәгәннәр. Суд та эшмәкәр яклы булып чыккан, ул бит, банкка мөрәҗәгатен язганда, канунны бозмаган. Банк, эш болай барса, клиентларын югалтачагын аңлап алып, гранит ташны ваткалап, тизрәк ишек каршын чистарттырган. Эшмәкәр икенче ризасызлыгын әзерләгәнче дип, туган бәхәсне хәл итеп, аңа ярдәм кулы сузу хәстәрен дә күргәннәр. Вакыйга дөрестерме-юктырмы, әмма игътибарга лаек, минемчә.

Менә чит илдән бер мисал. Швейцариядә бер бар хуҗасы, җәмәгать урыннарында һәм бина эчендә тәмәке тартуны тыючы канун кертелгәч, хәйләгә барган. Бар кунаклары уңайсызлык кичермәсеннәр өчен, ул өстәлләр янындагы диварларга ике кул һәм башны тыгып була алырлык тишемнәр эшләп куйган. Кеше үзе бина эчендә, әмма урамда тарта бит! Дино Лоттац исемле бу эшкуардан күреп, аннары башка кафе, бар хуҗалары да шулай эшли башлаганнар.

Россиядә дә 13 елдан алып 16 елга кадәр бөтен җәмәгать урыннарында, бина эчләрендә тәмәке тартуны тулысынча тыеп бетерергә җыеналар. Лоттац үрнәгендә безнекеләр арасында да, канундагы «тишек»тән файдаланып, стеналарга тишекләр ясап куючылар булмыйча калмас әле. Ул эшне вакытында тыймасалар, әлбәттә.

«Тишек»не ничек «ямарга»?

Канундагы «тычкан да, фил дә сыярлык» «тишекләр»не, яхшылап эзләгән очракта, кануннарның һәр төрендә табарга була. Язмада китерелгән мисаллардан тыш, аеруча зур һәм аферистлар тарафыннан нәтиҗәле файдаланыла торган төзексезлекләр сәүдә, төзелеш, йөкләр ташу өлкәләренә кагылышлы кануннарда, ана капиталын куллануны көйләүче канунда бар, Гражданнар кодексы белән юл йөрү кагыйдәләре бик еш бер-берсе белән «низаглашып» торалар. Искеләренә «ямау» салынган арада, аның яңалары барлыкка килергә өлгерә.

Ул «тишекләр» нәрсә аркасында туа соң? Төп сәбәп – кануннарның бик күп булуында. Бөтен әйберне алдан чамалап бетерү мөмкин хәл түгел бит. Яңа кануннарны гамәлгә керткәндә, элек кабул ителгәннәре белән исәпләшү, башкаларына каршылык тудырмыймы, комачауламыймы икәнен тикшерү, бик игътибарлы булу таләп ителә. Икенче сәбәп – кануннарның гел яңалары туып, искеләре гамәлдән чыгып, берсе өстенә берсе кабул ителеп торуында. Һәрхәлдә, кануннар бөтен җирдә тәртип булдыру өчен генә язылалар, әмма болай эшләүнең буталчыклык тудыруы бик ихтимал. Канундагы «тишекләр»нең игътибарсызлык, ялгышлык, ашыкканлык аркасында да китүе бар. Нишләтәсең, болар һәммәсе дә кеше факторлары, алар һәркайсыбызга хас. Әйткәнемчә, кануннарда төзексезлекләр, хаталар, аферистлар үз файдаларына куллана алырлык чи урыннар булмавын күзәтү бик авыр, четерекле эш һәм Россия әлегә ул хезмәткә әзер түгел.

... Апам белән кечкенә вакытта кием-салымнарыбызны әбинең күз уңынан ерактарак тотарга тырыша идек, чөнки әби берәр сүтек урын, тишек яки ертык күрсә, шунда ук аны тегеп яки ямап куя. Ямаулык материалны каян ала дигән әле – бала чагымда арткы кесәсе тездәге яки бот арасындагы ертыкка ямалмаган берәр чалбарым калган булдымы икән?! Бездән соң сеңлебез дә «киемнәрне аяк астында калдырырга ярамый» мәктәбен узды. Бөтен әбиләр дә үз оныкларына һәм аларның киемнәренә карата безнең әби кебек бик кайгыртучан була торганнардыр инде. Тишек киемне әби күреп алса, ул озак ямаусыз тормас, ә кануннардагы «тишекләр»не нишләтергә? Бу миссияне «ямау салу осталары» – әбиләр җилкәләренә йөкләсәләр, алар каршы килмәс килүен, ул күпсанлы канун «тишекләр»ен ямарга җитәрлек арткы кесәләрне генә каян табарга?

> Тозакка йозак куймыйлар.
> *Бибәл Норел*

АРЧА ЫМЛЫГЫ

Рафаэль СИБАТ

1968 ел...

Казан университетында укыган Зөлфәт, Раф Хуҗин һәм Арча ягы егете Сәетҗан белән Чистай мишәре Әмир Дәминов кайсыдыр фәннән уңышлы гына имтихан биргәннәр. Болар дүртесе бергә җыелганнар да:

– Их! Дүрт борынга Кәүсәр чишмәсенең дүртенче суын иснәтәсе иде, – диешкәннәр.

– Ике кетшегә бер тчирек зәм-зәм күпме генә тора инде, молойлер! – дигән саф мишәр телендә Әмир, озын чалбарының тар кесәсен капшап.

– Миндә тиен дә юк! – ди шагыйрь Зөлфәт, гадәтенчә, һәм, Чистай егете бер кесәсен кашып маташкан арада, ике кесәсен дә куян тиресе кебек әйләндереп сала.

Шулчак Вятка малае Раф Хуҗин, үзенчә бер кызулык белән, кичке ашка дигән соңгы тиеннәрен чутлый башлый, аны Сәетҗанның:

– Әй-әй! – дигән күп мәгънәле Арча ымлыгы гына туктата. Шушы ымлык барысын да хәл итә, аны ишетүгә, колаклары бурзай этнеке кебек торган соры-зәңгәр күзле Зөлфәт, бөдрәләрен селкетеп, Сәетҗанның уйчан, фәлсәфи карашлы, сөрмәле күзләренә бага:

– Сәетҗан, син Күәмнән, Мөхәммәт абый Гөберчәкнеке! Аңлыйсыңмы?

– Шуннан? – ди тегесе.

– Сез якташлар бит!

– Булса ни, – ди Сәетҗан уйчан гына.

– Соң, якташтан теләсә кайчан өч сум алып торырга була ич!

– Ул сине укытса, университет доценты булса дамы?! – дип мантыйкка терәмәкче була дусты.

– Их, безнең шундый якташ булсамы? Безнең хәлне кафедрада аннан да яхшы аңлаган кеше юк. Сора гына, бирә ул, ач икәнебезне аңлат! Бар ышаныч синдә!

Соңгы сүзләрдән Сәетҗанга батырлык иңә һәм ул татар әдәбияты кафедрасында нидер язып утыручы доцент Мөхәммәт Мәһдиев янына юнәлә. Ишеген дә япмыйча, ярты-лаш ачык калдырып, килеп керә бу:

– Мөхәммәт абый!

– Тыңлыйм, – ди Мәһдиев, башын күтәреп һәм бер кавымга язуыннан туктап.

– Менә... имтиханнар тапшырдык...

Сәет шулай күплектә сөйләшергә ярата, бер имтихан бирсә, имтиханнар, дияр иде.

– Бик яхшы булган!

Кыска җөмлә белән турыдан-туры эшкә керешүдән өмет юклыгын сизгән Сәетҗан Хәкимҗанов сүзне ерактан чолгый башлый:

– Студентлар тормышлары инде ул, Мөхәммәт абый, әй-әй...

Менә шунда укытучысы үгезне мөгезеннән ала:

– Озаклап тыңлап утырырга вакытым юк, Сәетҗан. Күпме?

– Нәрсә күпме? – ди сүз йөрешен югалткан егетебез.

– Син бит әҗәткә акча сорарга кердең. Ничә сум кирәк, дим.

– Ә?! Әй-әй. Дүрт кешеләргә... ө-ө-өч кенә... сумнар... Мөхәммәт абый.

Мәһдиев, берни булмагандай, гүя кәгазь кисәген чүп савытына ташларга җыена, кесәсеннән өч сум акча чыгарып бирә. Шунда ишек артындагы шәкертләрнең җанына җылы иңә, ә ашказаннары нидер кыздыргандай итеп кытыклап ала. Сәетҗан, рәхмәт әйтергә дә онытып, ишеккә ташлана. Шулчак язуына кадалган Мәһдиев башын күтәрә:

– Сәетҗан!

– Әү, Мөхәммәт абый...

– Туктале, ашыкма.

Менә ул кәчтүм кесәсенә кереп китә һәм аннан өч егерме тиен, бер ике тиен алып Сәетебезгә суза:

– Мә! Кибеттә бер тиен тулмаса да бирмиләр. Беләм бит, әле сезнең кабарлык алырга да... Ярый, ул нәрсә белән артык мавыкмагыз!

Сәетҗанның кояштай йөзенә коридорга чыгуга болыт куна, фәлсәфи карашка сагыш-моң иңә. Ә теге өч исәр сыгыла-сыгыла көлеп маташа.

Кибет ягына юл алуга, нигәдер Сәетҗанның сөмсере коела. Һәм ул, Зөлфәт ягына усал карап, әйтеп куя:

– Хурлар иттегез! Күзләре үк: «Беләм бит мин синең ни өчен акча сораганны», – дип карый ич аның...

Аннан, кулын селкәп, иптәшләреннән алгарак чыга да, Арча ымлыгын эшкә җигә:

– Әй-әй!

1996

Пародия

Ләбиб ЛЕРОН

Болында

> Мин болында ятам. Борыныма
> Килеп куна ялгыз күбәләк...
>
> **Рашат Низами**

Мин гашыйкмын гүзәл табигатькә –
Гел ятасы килә болында.
Шул болында яту уе белән
Авылыма кайттым быел да...

Бигрәкләр дә сагынганмын икән
Шәрә чагым – балачагымны:
«Ә» дигәнче чирәм өсләренә
Салып аттым кием-салымны.

Күккә карап, хозурланып ятам –
Борыныма куна күбәләк.
– Без дә синә гашыйк, Рашат! – диеп,
Кырмыскалар биттән үбәләр.

Кигәвеннәр гөжләп очкан була,
Тезгә кунган була әрсезе.
Куарга да өлгермичә калам,
Тешләп киткән була мәнсезе.

Тешләсәләр, әйдә, тешләсеннәр –
Андыйларга исем китми лә...
Иң мөһиме – мин болында ятам! –
Рәхәтлеккә берни җитми лә.

– Якташ, сиңа шигъри сәлам! – диеп
Бер кош очып китте ялгызы...
..Маңгаемда нинди тамчы, дисәм...
Шул кош киткән икән тамызып.

Тукранбаш дип белгән инде әллә –
Бер бал корты килгән, күр инде...
– Шәрә ятма, җүнсез! – диде дә ул,
Чагып китте нечкә җиремне...

2002

ЭПИГРАММА

Х. ФАЛИ (Фаил Шәфигуллин)

Мөдәррис Әгъләмовка

– Кайда яшәп, кайда эшләвемнең
Нинди катнашы бар биредә, –
Классик дигән бөек исем безгә
Иҗат өчен генә бирелә.

(Язучыларның «Тынгысыз каләм» дигән дивар газетасыннан. 1974.)



Мәзәкият

Данил САЛИХОВ

ТАТАР ЙӨРӘГЕ

Мәрхүм драматург Шамил Шаһгали (1920-1987), тәүге әсәрен күтәреп, режиссер Марсель Сәлимҗанов янына килә. Әсәрдә унҗиде персонаж катнашырга тиеш була. Шуларның унбише әсәр азагына таба үзара ызгышып, сугышып, бер-берсен үтерешеп бетерә. Исән калган икесе дуэльгә чыгып, берсе икенчесен атып үтерә. Иң соңгы герой дилбегә буе монолог сөйли дә үз-үзен чәнчеп үтерә.

Режиссер озак кына башын иеп утыра да:

– Гафу ит, Шаһгали. Моңа татар йөрәге чыдамас, – диеп, драматург иптәшнең әсәрен кире бора.

1996

Пенсия алган көн

Мөхәммәт МИРЗА

ХИКМӘТЛЕ ДҮРТЬЮЛЛЫКЛАР

Замананы хурлый-хурлый,
аласын алды барыбер:
тау башына, урлый-урлый,
таш пулат салды барыбер.

* * *

Булган су тегермәне,
булган җил тегермәне –
аларын юган вакыт,
калган тел тегермәне...

* * *

Җаны теләгәнгә – елан ите,
Күгәрченкәй сөте кемнәргә?
Ил казнасын талый эте-бете,
Хуҗасы үләр-үлмәс көннәрдә...

Кызыклы ракурс



Шагыйрь Рашат Низами каеннарга шигырь укый...

Сәхифәне Ләбиб ЛЕРОН әзерләде



Әниләрен урамда калдырдылар

Кайчандыр Надирәдән дә бәхетле кеше юк иде. Яраткан эшендә эшләде, яраткан кешесе белән яшәде. Җәйге ялларын бергәләп кайда гына үткәрмәделәр алар. Таныш-белешләре дә: «Бу Сайгановлар бармаган ял йорты калдымы икән әле?» – дип шаярталар иде. Аларның күршесе булган танышым Вәсилә дә мактап туймады үзләрен.

ТӘКЪДИР СЫНАВЫ

Люция ХӘБИБУЛЛИНА

Надирә белән бер-берсенә эч серләрен сөйләп, киңәшләшеп яшәде алар. Моннан берничә ел элек Вәсилә бердәнбер кызын югалткач та, күршесе аның терәге, юатучысы булды. Аннары Надирәнең ишеген дә бер-бер артлы кайгы җиле шакый.

Башта әнисен соңгы юлга озата. Аннары ире Сәгыйть хатынын икесе бергә салган йортларын сатарга күндерә. Акчаларының күбесен кызларына бүлеп бирәләр. Сәгыйть, калган акчасын кесәсенә салып, үзеннән ун яшькә яшьрәк хатынга китеп бара. Кызлары да беркайчан шөкер итә белми торганнардан булып чыга, җитмәсә. Ата-ана матур киендереп, тәмле ашатып үстерә үзләрен. Җәйге ялларын да әби-балалары янында түгел, лагерьларда үткәрә кызлар. Мәктәптән соң акча түләп югары уку йортларында укыталар, туйлар ясыйлар. Өчәр бүлмәле фатирларда яшәсәләр дә, соңгы бер-ике елда әниләренә тынычлап яшәргә ирек бирми кызлар. Аның ике бүлмәле фатирда берүзе яшәвенә эчләре поша башлый. Янына да хәл белергә түгел, ә фатирын сатарга кушып тавыш чыгарырга гына киләләр. Күршеләре Вәсилә аларның әниләрен мәсхәрәләп кычкыруларына түзә алмыйча яннарына кереп, аңлатып та карый. Ничек кенә рәнҗесә дә, Надирә кызларын каргамый. Елый-елый: «Ичмаса, теге чакта юл һәлакәтендә барыбыз бергә беткән булсак, мондый хәлләрне күзләрем күрмәс иде», – дип еш такмаклый хатын.

> ***Ничек кенә рәнҗесә дә, Надирә кызларын каргамый. Елый-елый: «Ичмаса, теге чакта юл һәлакәтендә барыбыз бергә беткән булсак, мондый хәлләрне күзләрем күрмәс иде», — дип еш такмаклый хатын***

Балалары мәктәптә укыганда ял итәргә барган җирдән бик каты юл һәлакәтенә очрый алар. Надирәнең күзләрен ачуга әйткән беренче сүзе: «Балалар исәнме?» – була. Ана кеше өч ай буе хастаханәдә көнетөне кызлары яныннан китми. Аларның кыл өстендәге тормышларын саклап калу өчен шактый акчалар түгәләр. Әнә шул балаларының икесе дә таш бәгырьле булып үсүенә гаҗәпләнә Надирә. Бүген инде үзләре ана булган кызлар әниләрен яшәү урынынннан мәхрүм иттеләр. Әтиләре Сәгыйтькә йөрәк өянәге булганнан соң, аның яшь хатынга кирәге калмый. Кире хатыны янына әйләнеп кайтырга горурлык дигән нәрсә комачаулый, күрәсең. Кызларга бу җитә кала. Алар әниләренең ике бүлмәле фатирын саттырып, әтиләренә бер бүлмә алып бирәләр. Үзләренә дә аннан өлеш чыгаралар. Әниләренең язмышы гына борчымый үзләрен. Надирә урамда кала. Әле аңа 57 генә яшь. Үз көнен үзе күрер хәлдә булса да, гомер буе эшләп тапканнарының бер мизгелдә юкка чыгуына нык борчыла ул. Балалары өстеннән суд юлларында йөрүдән хурланып, үзенең туганнары яшәгән Волжск шәһәренә китәргә мәҗбүр була.

Инде кызларның үз балалары да буй җитеп килә. Әниләренең шундый мәрхәмәтсез булуларын күреп үскән ул балалар киләчәктә аларга шәфкать күрсәтерме, әлегә билгесез.

Тукта, вакыт, тукта, бер минутка!..

– Шул Раязның җырын такмаклап кына яшим инде мин, – диде Гөлгенә, яшьләренә буыла-буыла. – Эх, кырык биш яшеңдә шушы көндә кал да, туганнарың бар дип тә белмәсеннәр инде! Ходай Тәгалә байлыкны, җитешлекне сынар өчен генә биргәнен алдан укыган, дини китапларны кулыма тормышым ялт итеп торган чакта алган булсаммы...

ГЫЙБРӘТ ӨЧЕН

Гөлнара ҖӘЛИЛОВА

Мин үземне яратып кияүгә чыктым дип әйтә алмыйм, – дип дәвам итте ул сүзен. – Ирем – Азатым ярата иде. Мин көйсез кияү белән бер – әй тинтерәтәм моны: алай итмә, болай ит, янәсе. Параллель рәвештә иптәш кызларга киңәшен дә мулдан бирәм – ирне күпме кадерсезләп тотсаң, ул сиңа шуның кадәр әйбәт була. Гаилә тормышыбызның җиде елы шулай узды да. Эшемне ташладым, Азатны икешәр эштә эшләттем. Улым, соңрак ике игезәгебез – кыз белән малай туды. Кызыбызның туу белән башына кан сауды. Бер тере бала, бер үле бала алып чыктык хастаханәдән. Шәп яшибез инде үзебезчә – машиналар йөреп тора, өй җиткерде Азат. Мин әле монысын, әле тегесен сорап кына торам. Алып кайта. Әти-әни белән аралашып торсак та, өч туганым белән араны өздем. Безнең бай дуслар арасында алар артык хәерче булып күренәләр иде. Азат оялмады алардан, мин оялдым – киеп киләләр кычкырып торган базар сәләмәсе, энемнең, елмаеп җибәрсә, алдагы алтын коронкалары ыржаеп утыра. Апаларым белән дә аралашуны туктаттым диярлек – берсенең ире мәҗлестә әйбәт кенә утыра алмый, ике рюмка эчсә исерә. Икенчесенең трамвай йөртүчесе ник минем ефәк паласым өстендә йөрсен ди әле?! Башта алар туган хакын хаклап кунакка дәшәләр иде, соңрак үзләре дә чакырмый башлады.

Улларыбыз әйбәт бакча-мәктәпкә йөрде, мин иркә һәм явыз хатын булдым. Иремнең өстемнән йөрүе турында уйлап та карамадым. Туганнарым белгән, әмма аралашмагач, миңа каян килеп ишетелсен инде ул? Көзге белән плитәдән башканы күрмәгән, өй хезмәтчеләренә фәрман бирүдән тыш мәшәкатьләргә күмелмәгән хатын үзеннән дә яхшырак зат булуы мөмкин дигән уйлар белән ваклана-мы соң инде? Чит хатын белән яшәячәген ул уртак балалары тугач кайтып әйтте. Мин терелэй үлдем. Иртәнгә буялган чәчем астыннан ап-ак җәймә бүртеп чыккан иде. Тыныч кына киемнәрен җыйды, «Син кабахәт хатын. Юньле булсаң, үз туганнарыңны ким-хур итмәс, агуыңа буылып берүзең өйдә утырмас идең. Мин кешелекле хатынны яраттым. Өйне бүлешеп тормыйм, сиңа калдырам», – диде. Һәм минем өчен дөнья да, вакыт та үз күчәреннән чыгып туктап калды.

> ***«Син кабахәт хатын. Юньле булсаң, үз туганнарыңны ким-хур итмәс, агуыңа буылып берүзең өйдә утырмас идең. Мин кешелекле хатынны яраттым. Өйне бүлешеп тормыйм, сиңа калдырам», — диде.***

Бер-ике атна елый-елый юләрләнә язгач, бераз айнычым шикелле. Иң беренче өйдә акча бетте. Азат балаларның укуларына түләгән, ә коммуналь хезмәтләр өчен килгән сигез мең сум бурычны нишләтергә? Шалтыратам моңа. Акча кирәк, дим. «Акча кирәк кеше эшкә чыга», – дип коры гына җавап кайтарды Азат. Идән юучы булып эшкә урнаштым. Син мине күрсәң – подъезд идәне юам, үземнең юган идәнгә тыптып яшем тама. Бармак саен алтын йөзек, колакта сиксән меңлеге «елмая» – ә мин кеше шакшысы, кеше төкереге юып йөрим. Башта апага шалтыраттым. Ул, илтифатсыз гына: «Кире кайтыр әле, сабыр ит», – диде дә, башка аралашасы килмәгәнлеген ассызыклап, телефонын сүндереп тә куйды. Икенче апа да, энекәш тә минем кайгыга егылып китмәделәр. Башың исән булсын, имеш. Ашарыңа булмагач, ул башның ни кирәге бар? Өйне сатарга куйдым. Кем алды диген әле син аны? Уртанчы апа. Баксаң, фатир киңәйтергә дип акча җыйган булганнар, мин сиңа әйтим... Мин ике бүлмәле фатир алдым. Өй сатудан калган кулдагы акчага бер еллап иркен яшәдем әле. Анысы бетүгә, кабат эш эзли башладым. Беренчедә укучы кечкенә улым минем белән фатирга күченде. Зурысы әтисе белән яшәүне хуп күрде.

Авыр миңа, бик авыр. Азатның хыянәтенә дә күндем бугай инде. Туганнарымны гомерлеккә югалту җанны әрнетә. Бер абыстай: «Байлык кешене сынар өчен генә бирелә», – диде әле үземә. Алданрак белсәм, мин дә, бәлки, бу көнгә калмас идем. Ирем юк, балаларга кирәгем шул хәтле генә, туганнарым миннән йөз чөергән. Аралашыр кешем дә юк. Заводтагы бушка сөяркә эзләп йөрүче ирләр белән дә вакланасым килми. Мин бит хәзер вахтада утырам – аена 9 мең 500 сум хезмәт хакы чыга. Шуңа бер ай яшим. Ә ул акча, ирле булганда, минем бер тапкыр кибеттә калдырып чыга торган «мелочь» иде...

ЯРДӘМ КИРӘК

НӘНИ МӘРЬЯМГӘ БЕРГӘЛӘП БУЛЫШЫЙК

Моннан дүрт ел элек татар җыр дөньясына ышанычлы адымнар белән килгән, аеруча яшьләр күңеленә тиз арада юл тапкан автор-башкаручы Миләүшә Сафина, радио-телевидение аша җырлары яңгырый башлаган, үз иҗатына игътибар көчәйгәннән-көчәя барган мизгелдә, язмышның алда нинди сынаулар әзерләгәнен каян белсен инде.... Ул Татар яшьләр форумы, «Сәләт» хәрәкәте оештырган чараларда актив катнашып килә, Татарстаннан читтәге милләттәшләребез алдында да чыгышлар ясый. «Болгарны тыңласаң, үзеңне ишетерсең» конкурсында да җиңү яулый. Кыскасы, яшь кызның үз тырышлыгы, үз сәләте белән танылу үренә күтәрелүе башлана.

Аннан гаилә кору, кызы Мәрьям туу шатлыгы... Тик бала туган вакытта, саксызлык аркасында, имгәнү ала. 5 айдан соң Мәрьямнең үсешендә тоткарлыклар килеп чыга. Эпилепсия өянәкләре башлана. Терәк-хәрәкәтләнү системасы зарарлана.

Бүген ике яшьлек Мәрьям Сафинага Россия табиблары гына ярдәм итә алмый. Чит илдә дәвалау курслары узу сорала. Ә бу, ким дигәндә, миллион ярымга төшәчәк. Яшь гаилә күтәрә алырлык сумма түгел.

Миләүшәнең дуслары, бу күңелсезлек турында ишетеп, киң колачлы эш җәелдерде. Социаль челтәрләрдә нәни Мәрьямгә ярдәм итү өчен махсус төркем төзелгән, сайт ачылган. 20 көн эчендә игелекле кешеләрдән 300 мең сум ярдәм җыелган да инде. 31 гыйнварда яшьләр Мәрьям өчен дискотека уздыра. 10 февральдә исә Казанның филармония залында «Чын йөрәктән» исемле хәйрия концерты узачак. Хәйрия чарасына сатылган билетлардан кергән барлык сумма Мәрьямне дәвалау өчен күчереләчәк.

Яндекс деньги:
410011721176776

WebMoney
R327644824079 рубли
E101180933499 евро
Z169293447158 доллары

Киви кошелек
9509491936

Билайн-деньги
8962559064 или *89625558957*

ДҮШӘМБЕ
4 ФЕВРАЛЬ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05.00 «Манзара». (6+)
07.25 «Дин вә хәят» (6+)
07.30 «Доброе утро!»
08.30, 00.30 Т/с «ДВЕ СЕСТРЫ» (12+)
09.30, 17.30 Т/с «МӘХӘББӘТ ШӘРАБЫ» (12+)
10.30, 01.30 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
11.00, 02.00 «Җырлыйк әле!» (6+)
12.00, 22.00 Т/с «ЭЗЕЛЬ» (16+)
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа (12+)
14.00, 18.30, 21.30 Новости Татарстана (12+)
14.20 «Реквизиты былой суеты» (12+)
14.40 «Һөнәр» (6+)
14.55 «Тиззарядка» (0+)
15.00, 21.15 «Хочу мультфильм!» (0+)
15.15, 21.00 «Күчтәнәч» (0+)
15.30 «Тамчы-шоу» (6+)
16.00 «Җырлыйбыз да биибез» (0+)
16.25 Т/с «ЭНИД БЛАЙТОН: СЕКРЕТНАЯ КНИГА»
17.00, 20.00 Татарстан хәбәрләре (12+)
17.20 «Елмай!» (12+)
19.00 «Наш дом – Татарстан». Премьера телефильма «Мы едины» (12+)
19.15 Д/ф «Муса Джалиль. Возвращение поэта» (12+)
19.45 «Бизнес Татарстана» (12+)
20.30 «Халкым минем...» (12+)
23.00 Т/с «БЛИЗНЕЦЫ» (12+)

ТАТАРСТАН
06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
11.30 «Парламентские вести»
14.30, 17.30, 19.40 «Вести-Татарстан»

1 КАНАЛ
05.00, 09.00, 03.00 Новости
05.05 «Доброе утро»
09.15 «Контрольная закупка»
09.45 «Жить здорово!» (12+)
10.55 «Модный приговор»
12.00, 15.00 Новости (с субтитрами)
12.20 «Время обедать!»
13.00 «Доброго здоровьица!» с Геннадием Малаховым (12+)
14.00 Другие новости
14.25 «Понять. Простить» (12+)
15.15 «Хочу знать»
15.50 «Ты не один» (16+)
16.20 «Дешево и сердито» с Дарьей Донцовой
17.00 Т/с «НЕРАВНЫЙ БРАК» (16+)
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.50 «Давай поженимся!» (16+)
19.50 «Пусть говорят» (16+)
21.00 «Время»
21.30 Т/с «ГРАЧ» (16+)
23.30 «Вечерний Ургант» (S) (16+)

РОССИЯ
05.00 Утро России
09.00 «1000 мелочей». Ток-шоу
09.45 «О самом главном». Ток-шоу
10.30 «КУЛАГИН И ПАРТНЕРЫ». (12+)
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 14.30, 17.30, 19.40 Вести-Татарстан
11.50 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ». (12+)
12.50 «Дело Х. Следствие продолжается». Ток-шоу. (12+)
13.50, 16.45 Вести. Дежурная часть
14.50 Т/с «ЕФРОСИНЬЯ. ТАЁЖНАЯ ЛЮБОВЬ»
15.45 Т/с «ТАЙНЫ ИНСТИТУТА БЛАГОРОДНЫХ ДЕВИЦ»
17.50 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ-11». (12+)
20.30 Спокойной ночи, малыши!
20.40 «Прямой эфир». (12+)
21.30 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ-12». (12+)
23.15 «Дежурный по стране». Михаил Жванецкий

НТВ
06.00 Информационный канал «НТВ утром»
08.10 Т/с «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» (16+)
10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня
10.20 «Живут же люди!» (0+)
10.55 «До суда» (16+)
11.55 Суд присяжных (16+)
13.25 «Суд присяжных. Окончательный вердикт» (16+)
14.35 Т/с «СУПРУГИ» (16+)
15.30, 18.30 Обзор. Чрезвычайное происшествие
16.25 «Прокурорская проверка» (16+)
17.40 «Говорим и показываем». Ток-шоу с Леонидом Закошанским (16+)
19.30 Т/с «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (16+)
21.30 Т/с «ОДИНОКИЙ ВОЛК» (16+)
23.15 Сегодня. Итоги
23.35 Х/ф «БРИГАДА» (18+)

ЗВЕЗДА
06.00 «Лучшие воинские части» (16+)
06.10 Итоги недели
07.05 Х/ф «БЕЗ ПРАВА НА ОШИБКУ» (16+)
09.00, 13.00, 16.00, 18.00, 22.00 НОВОСТИ
09.25 Д/с «Победить рак» (12+)
13.15 Д/ф «Дальняя авиация» (12+)
14.00, 19.00, 21.30 Новости «Столица» (KZN) (0+)
14.15 Т/с «НА ВСЕХ ШИРОТАХ...» (12+)
16.20 Х/ф «ЧАКЛУН И РУМБА» (12+)
18.50, 21.20 «Чрезвычайка» (KZN) (16+)
19.30 Т/с «ГРУППА «ZETA» (16+)
22.30 Т/с «СТАВКА БОЛЬШЕ, ЧЕМ ЖИЗНЬ» (12+)

КУЛЬТУРА
07.00 «Евроньюс» на русском языке
10.00 «Наблюдатель»
11.15, 22.40 Х/ф «70 ЛЕТ ПОБЕДЫ ПОД СТАЛИНГРАДОМ. «ЖИЗНЬ И СУДЬБА»
13.50 Д/ф «Хранители Мелихова»
14.20 Д/ф «Мария Монтессори»
15.10 «Пешком...» Москва театральная
15.40, 19.30, 00.15 Новости культуры
15.50 Спектакль «ПУШКИН. ДУЭЛЬ. СМЕРТЬ»
17.05 К 90-летию со дня рождения Михаила Курилко-Рюмина. «Эпизоды». (*)
17.50 Виртуозы гитары. Лиа Коэн
19.00 Д/с «Великий перемол, или Академическое дело»
19.45 Главная роль
20.05 «Сати. Нескучная классика...» с митрополитом Иларионом и Светланой Касьян
20.50 Д/с «Запечатленное время». «Обреченная экспедиция»
21.15, 01.40 Д/ф «Чудовище Млечного Пути»
22.10 Д/с «Лия Ахеджакова. Обаяние отваги»
00.35 Д/ф «Актуальное кино с Людмилой Улицкой». «Посылки по воскресеньям». «Мигрантка»

ЭФИР
05.00 «УТРО» (16+)
08.30, 12.30 «Новости 24» (16+)
09.00 Т/с «БЕЛЫЕ ВОЛКИ»
10.00 Концерт «Будь готов!»
12.00, 23.00 «Экстренный вызов» (16+)
13.00 «Званый ужин» (16+)
14.00 «Засуди меня» (16+)
15.00 «Семейные драмы» (16+)
16.00, 17.00 «Не ври мне!» (16+)
18.00 «Верное средство» (16+)
19.00, 22.00 «Информационный час: Программа ГОРОД» (16+)
20.00 ПРЕМЬЕРА. «Военная тайна с Игорем Прокопенко» (16+)
23.30 «Новости 24» Итоговый выпуск (16+)
23.50, 02.40 Х/ф «ИГРЫ КИЛЛЕРОВ»
01.50 Т/с «СВЕРХЪЕСТЕСТВЕННОЕ»

СТС-КАЗАН
06.00 М/с «Гуфи и его команда»
07.00 М/с «Скуби Ду. Корпорация «Тайна»
07.30 М/с «Чародейки» (12+)
08.00, 00.00 Т/с «ДАЁШЬ МОЛОДЁЖЬ!» (16+)
09.00, 13.15, 13.30, 17.45, 01.30 Т/с «6 КАДРОВ» (16+)
09.30 Д/ф «История российского юмора» (16+)
10.30, 18.30 «ВОРОНИНЫ» (16+)
11.30 М/ф «Пропавший рысёнок» 2008 г. (12+)
14.00 Х/ф «МОЯ УЖАСНАЯ НЯНЯ-2»
16.00 М/Ф «Монстры против пришельцев». (12+)
18.00, 20.00 «ВОСЬМИДЕСЯТЫЕ» (16+)
19.00 «КУХНЯ» (16+)
21.00 «СВЕТОФОР» (16+)
22.00 Х/ф «ФОРСАЖ» (16+)

СПОРТ
05.00, 07.45 «Все включено» (16+)
05.50, 01.50 «Моя планета»
06.35 «В мире животных» с Николаем Дроздовым
07.05, 09.00, 12.15, 17.45 Вести-спорт
07.15 «Моя рыбалка»
08.40, 11.55 Вести.ru
09.10 Х/ф «ПОДСТАВА» (16+)
10.55 «Наука 2.0. Большой скачок». Психолингвистика
11.25 «Наука 2.0. Большой скачок». Тайны крови
12.45 «Футбол.ru»
13.30 Шорт-трек. Кубок мира. Трансляция из Сочи
14.30 Х/ф «ОПАСНЫЙ БАНГКОК» (16+)
16.15 «Наука 2.0. ЕХперименты». Экранопланы
16.45 «Наука 2.0. ЕХперименты». Суда на воздушной подушке
17.15 «Наука 2.0. ЕХперименты». Укрощение воды
17.55 «ОТДЕЛ С.С.С.Р.» (16+)
21.30 «Гладиатор. Правда и вымысел» (16+)
22.25 Неделя спорта
23.20 Х/ф «ЛУЧШЕЕ ПРИКРЫТИЕ» (16+)
01.05 «Вопрос времени». Дефицит земли

СИШӘМБЕ
5 ФЕВРАЛЬ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05.00 «Манзара». (6+)
07.25 «Размышления о вере» (6+)
07.30 «Доброе утро!»
08.30, 00.30 Т/с «ДВЕ СЕСТРЫ» (12+)
09.30, 17.30 Т/с «МӘХӘББӘТ ШӘРАБЫ» (12+)
10.30, 01.30 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
11.00 «Башваткыч» (12+)
12.00, 22.00 Т/с «ЭЗЕЛЬ» (16+)
13.00, 19.00 Д/ф «Великие комбинаторы» (12+)
14.00, 18.30, 21.30 Новости Татарстана (12+)
14.20 «Аулак өй» (6+)
14.55 «Тиззарядка» (0+)
15.00, 21.15 «Хочу мультфильм!» (0+)
15.15, 21.00 «Күчтәнәч» (0+)
15.30 «Яшьләр тукталышы» (12+)
16.00 «Tat-music» (12+)
16.25 Т/с «ЭНИД БЛАЙТОН: СЕКРЕТНАЯ КНИГА»
17.00, 20.00 Татарстан хәбәрләре (12+)
17.20 «Елмай!» (12+)
20.30 «Туган җир» (12+)
23.00 Т/с «БЛИЗНЕЦЫ» (12+)
00.00 «Автомобиль» (12+)

ТАТАРСТАН
06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Современник». Софья Кузьминых
09.20 «Дорога к дому»
11.30, 14.30, 17.30, 19.40 «Вести-Татарстан»

1 КАНАЛ
05.00, 09.00, 03.00 Новости
05.05 «Доброе утро»
09.15 «Контрольная закупка»
09.45 «Жить здорово!» (12+)
10.55 «Модный приговор»
12.00, 15.00 Новости (с субтитрами)
12.20 «Время обедать!»
13.00 «Доброго здоровьица!» с Геннадием Малаховым (12+)
14.00 Другие новости
14.25 «Понять. Простить» (12+)
15.15 «Хочу знать»
15.50 «Ты не один» (16+)
16.20 «Дешево и сердито» с Дарьей Донцовой
17.00 Т/с «НЕРАВНЫЙ БРАК» (16+)
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.50 «Давай поженимся!» (16+)
19.50 «Пусть говорят» (16+)
21.00 «Время»
21.30 Т/с «ГРАЧ» (16+)
23.30 «Вечерний Ургант» (S) (16+)
00.00 Ночные новости «Городские пижоны»
00.20 Т/с «КАРТОЧНЫЙ ДОМИК» (S) (16+) «ГОРОДСКИЕ ПИЖОНЫ»

РОССИЯ
05.00 Утро России
09.00 «1000 мелочей». Ток-шоу
09.45 «О самом главном». Ток-шоу
10.30 «КУЛАГИН И ПАРТНЕРЫ». (12+)
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 14.30, 17.30, 19.40 Вести-Татарстан
11.50 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ». (12+)
12.50 «Дело Х. Следствие продолжается». Ток-шоу. (12+)
13.50, 16.45, 04.45 Вести. Дежурная часть
14.50 Т/с «ЕФРОСИНЬЯ. ТАЁЖНАЯ ЛЮБОВЬ»
15.45 Т/с «ТАЙНЫ ИНСТИТУТА БЛАГОРОДНЫХ ДЕВИЦ»
17.50 Т/с «ТОЧКА КИПЕНИЯ» (12+)
20.30 Спокойной ночи, малыши!
20.40 «Прямой эфир». (12+)
21.30 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ-12». (12+)
23.20 Специальный корреспондент. (16+)
00.25 Премьера. «Шарль де Голль. Его Величество президент»
01.20 Вести +

НТВ
06.00 Информационный канал «НТВ утром»
08.10 Т/с «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» (16+)
10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня
10.20 «Поедем, поедим!» (0+)
10.55 «До суда» (16+)
11.55 Суд присяжных (16+)
13.25 «Суд присяжных. Окончательный вердикт» (16+)
14.35 Т/с «СУПРУГИ» (16+)
15.30, 18.30 Обзор. Чрезвычайное происшествие
16.25 «Прокурорская проверка» (16+)
17.40 «Говорим и показываем». Ток-шоу с Леонидом Закошанским (16+)
19.30 Т/с «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (16+)
21.30 Т/с «ОДИНОКИЙ ВОЛК» (16+)
23.15 Сегодня. Итоги
23.35 Х/ф «БРИГАДА» (18+)

ЗВЕЗДА
06.00 «Дороже золота» (16+)
06.20, 18.50, 21.20 «Чрезвычайка» (KZN) (16+)
06.30, 14.00, 19.00, 21.30 Новости «Столица» (KZN) (0+)
07.10, 14.15 Т/с «НА ВСЕХ ШИРОТАХ...» (12+)
09.00, 13.00, 16.00, 18.00, 22.00 НОВОСТИ
09.15, 22.30 Т/с «СТАВКА БОЛЬШЕ, ЧЕМ ЖИЗНЬ» (12+)
11.35 «Освобождение». Документальный сериал. «Восточно-Прусская операция. Разведка (12+)
12.05, 19.30 Т/с «ГРУППА «ZETA» (16+)
13.15 Д/с «Невидимый фронт» (12+)
16.15 Т/с «ZОННЕНТАУ» (16+)

Адәм белән Һава

17.15 Д/с «ВВС. 100 лет и один день». «Полет на пределе. Из жизни истребителей» (12+)
01.05 Х/ф «В СТРЕЛЯЮЩЕЙ ГЛУШИ» (12+)

КУЛЬТУРА
06.30 «Евроньюс» на русском языке
10.00 «Наблюдатель»
11.15, 22.40 Х/ф «70 ЛЕТ ПОБЕДЫ ПОД СТАЛИНГРАДОМ. «ЖИЗНЬ И СУДЬБА»
12.45 Д/ф «Мировые сокровища культуры». «Абу-Мена. Ожидание последнего чуда»
13.05 «Сати. Нескучная классика...» с митрополитом Иларионом и Светланой Касьян
13.45 «Больше, чем любовь»
14.25 «Полиглот». Французский с нуля за 16 часов! №13
15.10 «Мой Эрмитаж». Авторская программа М. Пиотровского. (*)
15.40, 19.30, 00.15 Новости культуры
15.50 Спектакль «ПУШКИН. ДУЭЛЬ. СМЕРТЬ»
17.20 Д/ф «Чтоб играть на века...»
18.00 Виртуозы гитары. Гала-концерт
19.00 Д/с «Великий перемол, или Академическое дело»
19.45 Главная роль
20.05 Власть факта. Ближний Восток
20.50 Д/с «Запечатленное время». «Москва. Хроники Сталинской реконструкции»
21.15, 01.55 Д/с «Орбита: необыкновенное путешествие планеты Земля»
22.10 Д/с «Лия Ахеджакова. Обаяние отваги»
23.55 Д/ф «Мировые сокровища культуры». «Виченца. Город Палладио»
00.35 Д/с «Искусство Испании»

ЭФИР
05.00 «УТРО» (16+)
08.30, 12.30 «Новости 24» (16+)
09.00 Т/с «БЕЛЫЕ ВОЛКИ»
12.00, 23.00 «Экстренный вызов» (16+)
13.00 «Званый ужин» (16+)
14.00 «Засуди меня» (16+)
15.00 «Семейные драмы» (16+)
16.00, 17.00 «Не ври мне!» (16+)
18.00 «Верное средство» (16+)
19.00, 22.00 «Информационный час: Программа ГОРОД» (16+)
20.00 «Территория заблуждений с Игорем Прокопенко» (16+)
23.30 «Новости 24» Итоговый выпуск 16+
23.50, 02.45 Х/ф «ЗАКОНОПОСЛУШНЫЙ ГРАЖДАНИН»

СТС-КАЗАН
06.00 М/с «Гуфи и его команда»
07.00 М/с «Скуби Ду. Корпорация «Тайна»
07.30 М/с «Чародейки» (12+)
08.00, 10.30, 00.00 Т/с «ДАЁШЬ МОЛОДЁЖЬ!» (16+)
09.00, 09.30, 13.15, 13.30 Т/с «6 КАДРОВ» (16+)
10.00, 17.30, 20.00 «ВОСЬМИДЕСЯТЫЕ» (16+)
11.00, 18.00, 18.30 «ВОРОНИНЫ» (16+)
11.30 «Монстры против пришельцев». Полнометражный анимационный фильм (12+)
14.00 Х/ф «ФОРСАЖ» (16+)
16.00 м/Ф «Лесная братва». (12+)
19.00 «КУХНЯ» (16+)
21.00 «СВЕТОФОР» (16+)
22.00 Х/ф «ТРОЙНОЙ ФОРСАЖ. ТОКИЙСКИЙ ДРИФТ» (16+)

СПОРТ
05.00, 07.45 «Все включено» (16+)
05.50 «Вопрос времени». Дефицит земли
06.20, 01.50 «Моя планета»
07.05, 09.00, 12.15, 17.45, 22.55 Вести-спорт
07.15 «Диалоги о рыбалке»
08.40, 11.55, 01.35 Вести.ru
09.10 Х/ф «СТАЛЬНЫЕ АКУЛЫ» (16+)
10.55 «Наука 2.0. Большой скачок». Жаропрочные сплавы
11.25 «Наука 2.0. Большой скачок». Ростест. Испытания
12.25 «Братство кольца»
12.55 Х/ф «ПОДСТАВА» (16+)
14.40 Х/ф «ЛУЧШЕЕ ПРИКРЫТИЕ» (16+)
16.20 «Наука 2.0. НЕпростые вещи». Автомат Калашникова
16.50 «Наука 2.0. НЕпростые вещи». Путь скрепки
17.20 «Наука 2.0. НЕпростые вещи». Соль
17.55 «ОТДЕЛ С.С.С.Р.» (16+)
21.30 «IДетектив» (16+)
22.00 «Челюсти. Правда и вымысел» (16+)
23.10 Х/ф «МИФ» (16+)

ЧӘРШӘМБЕ
6 ФЕВРАЛЬ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05.00 «Манзара». (6+)
07.25 «Дин вә хәят» (6+)
07.30 «Доброе утро!»
08.30, 00.30 Т/с «ДВЕ СЕСТРЫ» (12+)
09.30, 17.30 Т/с «МӘХӘББӘТ ШӘРАБЫ» (12+)
10.30, 01.30 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
11.00 «Туган җир» (12+)
11.30 «Халкым минем...» (12+)
12.00, 22.00 Т/с «ЭЗЕЛЬ» (16+)
13.00 «Секреты татарской кухни» (12+)
13.30 «Среда обитания» (12+)
14.00, 18.30 Новости Татарстана (12+)
14.20 «Актуальный ислам» (6+)
14.25 «Нәсыйхәт» (6+)
14.55 «Тиззарядка» (0+)
15.00, 21.15 «Хочу мультфильм!» (0+)
15.15, 21.00 «Күчтәнәч» (0+)
15.30 «Без – Тукай оныклары» (6+)
15.45 «Һөнәр» (6+)
16.00 «Җырлыйбыз да биибез» (0+)
16.25 Т/с «ЭНИД БЛАЙТОН: СЕКРЕТНАЯ КНИГА»
17.00, 20.00 Татарстан хәбәрләре (12+)
17.20 «Елмай!» (12+)
19.00 «Кара-каршы» (12+)
20.30 «Яшьләр тукталышы» (12+)
21.30 Новости Татарстана
23.00 Т/с «БЛИЗНЕЦЫ» (12+)

ТАТАРСТАН
06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
11.30, 14.30, 17.30, 19.40 «Вести-Татарстан»

1 КАНАЛ
05.00, 09.00, 03.00 Новости
05.05 «Доброе утро»
09.15 «Контрольная закупка»
09.45 «Жить здорово!» (12+)
10.55 «Модный приговор»
12.00, 15.00 Новости (с субтитрами)
12.20 «Время обедать!»
13.00 «Доброго здоровьица!» с Геннадием Малаховым (12+)
14.00 Другие новости
14.25 «Понять. Простить» (12+)
15.15 «Хочу знать»
15.50 «Ты не один» (16+)
16.20 «Дешево и сердито» с Дарьей Донцовой
17.00 Т/с «НЕРАВНЫЙ БРАК» (16+)
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.50 «Давай поженимся!» (16+)
19.50 «Пусть говорят» (16+)
21.00 «Время»
21.30 Т/с «ГРАЧ» (16+)
23.30 «Вечерний Ургант» (S) (16+)
00.00 Ночные новости «Городские пижоны»

РОССИЯ
05.00 Утро России
09.00 «1000 мелочей». Ток-шоу
09.45 «О самом главном». Ток-шоу
10.30 «КУЛАГИН И ПАРТНЕРЫ». (12+)
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 14.30, 17.30, 19.40 Вести-Татарстан
11.50 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ». (12+)
12.50 «Дело Х. Следствие продолжается». Ток-шоу. (12+)
13.50, 16.45, 04.45 Вести. Дежурная часть
14.50 Т/с «ЕФРОСИНЬЯ. ТАЁЖНАЯ ЛЮБОВЬ»
15.45 Т/с «ТАЙНЫ ИНСТИТУТА БЛАГОРОДНЫХ ДЕВИЦ»
17.50 Т/с «ТОЧКА КИПЕНИЯ» (12+)
20.30 Спокойной ночи, малыши!
20.40 «Прямой эфир». (12+)
21.30 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ-12». (12+)
23.25 Футбол. Товарищеский матч. Россия – Исландия. Прямая трансляция из Испании
01.25 Вести +

НТВ
06.00 Информационный канал «НТВ утром»
08.10 Т/с «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» (16+)
10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня
10.20 «Чудо техники» с Сергеем Малозёмовым (12+)
10.55 «До суда» (16+)
11.55 Суд присяжных (16+)
13.25 «Суд присяжных. Окончательный вердикт» (16+)
14.35 Т/с «СУПРУГИ» (16+)
15.30, 18.30 Обзор. Чрезвычайное происшествие
16.25 «Прокурорская проверка» (16+)
17.40 «Говорим и показываем». Ток-шоу с Леонидом Закошанским (16+)
19.30 Т/с «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (16+)
21.30 Т/с «ОДИНОКИЙ ВОЛК» (16+)
23.15 Сегодня. Итоги
23.35 Х/ф «БРИГАДА» (18+)
00.40 Т/с «ДЕМОНЫ» (16+)
01.40 Квартирный вопрос (0+)

ЗВЕЗДА
06.00 «Дороже золота» (16+)
06.20, 18.50, 21.20 «Чрезвычайка» (KZN) (16+)
06.30, 14.00, 19.00, 21.30 Новости «Столица» (KZN) (0+)
07.10, 14.15 Т/с «НА ВСЕХ ШИРОТАХ...» (12+)
09.00, 13.00, 16.00, 18.00, 22.00 НОВОСТИ
09.15, 22.30 Т/с «СТАВКА БОЛЬШЕ, ЧЕМ ЖИЗНЬ» (12+)
12.05, 19.30 Т/с «ГРУППА «ZETA» (16+)
13.15 Д/с «Невидимый фронт» (12+)
16.15 Т/с «ZОННЕНТАУ» (16+)
17.15 Д/с «ВВС. 100 лет и один день». «Из ночи в день перелетая. От бомбардировщика до ракетоносца» (12+)
00.45 Х/ф «БЕЗ ОСОБОГО РИСКА» (12+)

КУЛЬТУРА
06.30 «Евроньюс» на русском языке
10.00 «Наблюдатель»
11.15, 22.40 Х/ф «70 ЛЕТ ПОБЕДЫ ПОД СТАЛИНГРАДОМ. «ЖИЗНЬ И СУДЬБА»
12.35 Д/ф «Алтайские кержаки»
13.05 Власть факта. Ближний Восток
13.45 «Больше, чем любовь»
14.25 «Полиглот». Французский с нуля за 16 часов! №14
15.10 Красуйся, град Петров! Зодчие Гаэтано Киавери и Савва Чевакинский. (*)
15.40, 19.30, 00.15 Новости культуры
15.50 Спектакль «ПИР ВО ВРЕМЯ ЧУМЫ». «У Никитских ворот»
17.35 «В эстетике маленького человека». Михаил Светин. (*)
18.00 Виртуозы гитары. Хуан Мануэль Канизарес
18.45 Важные вещи. «Пушечки Павла I»
19.00 Д/с «Великий перемол, или Академическое дело»
19.45 Главная роль
20.05 «Абсолютный слух». Альманах по истории музыкальной культуры
20.50 Д/с «Запечатленное время». «Правильная охота»
21.15, 01.55 Д/с «Орбита: необыкновенное путешествие планеты Земля»
22.10 Д/с «Лия Ахеджакова. Обаяние отваги»
23.55 Д/ф «Мировые сокровища культуры». «Кайруан. Священный город Магриба»

ЭФИР
05.00 «УТРО» (16+)
08.30, 12.30 «Новости 24» (16+)
09.00 Т/с «БЕЛЫЕ ВОЛКИ»
12.00, 23.00 «Экстренный вызов» (16+)
13.00 «Званый ужин» (16+)
14.00 «Засуди меня» (16+)
15.00 «Семейные драмы» (16+)
16.00, 17.00 «Не ври мне!» (16+)
18.00 «Верное средство» (16+)
19.00, 22.00 «Информационный час: Программа ГОРОД» (16+)
20.00 ПРЕМЬЕРА. «Нам и не снилось»: «Замужем за мафией» (16+)
23.30 «Новости 24» Итоговый выпуск (16+)
23.50, 02.30 Х/ф «ОДИССЕЙ И ОСТРОВ ТУМАНОВ»

СТС-КАЗАН
06.00 М/с «Гуфи и его команда»
07.00 М/с «Скуби Ду. Корпорация «Тайна»
07.30 М/с «Жизнь с Луи»
08.00, 13.00, 00.00 Т/с «ДАЁШЬ МОЛОДЁЖЬ!» (16+)
09.00, 09.30, 13.30 Т/с «6 КАДРОВ» (16+)
10.00, 17.30, 20.00 «ВОСЬМИДЕСЯТЫЕ» (16+)
10.30, 18.00, 18.30 «ВОРОНИНЫ» (16+)
11.30 «Лесная братва». Полнометражный анимационный фильм (12+)
14.00 Х/ф «ТРОЙНОЙ ФОРСАЖ. ТОКИЙСКИЙ ДРИФТ» (16+)
16.00 м/Ф «Подводная братва». (12+)
19.00 «КУХНЯ» (16+)
21.00 «СВЕТОФОР» (16+)
22.00 Х/ф «ФОРСАЖ-4» (16+)

СПОРТ
05.00, 07.45 «Все включено» (16+)
05.50 «Гладиатор. Правда и вымысел» (16+)
06.40, 03.05 «Моя планета»
07.05, 09.00, 12.15, 16.35, 21.45 Вести-спорт
07.15 «Язь против еды»
08.40, 11.55, 02.50 Вести.ru
09.10 Х/ф «ЛУЧШЕЕ ПРИКРЫТИЕ» (16+)
10.55 «Наука 2.0. Программа на будущее». Мир заселенного воздуха
11.25 «Угрозы современного мира». Жажда планетарного масштаба
12.25 «ОТДЕЛ С.С.С.Р.» (16+)
16.05 «Полигон»
16.45 Х/ф «ПАТРИОТ» (16+)
18.35 Футбол России
19.25 Хоккей. Евротур. «Шведские хоккейные игры». Россия – Финляндия. Прямая трансляция
21.55 Футбол. Товарищеский матч. Испания – Уругвай. Прямая трансляция
23.55 Футбол. Товарищеский матч. Англия – Бразилия

ПӘНҖЕШӘМБЕ
7 ФЕВРАЛЬ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05.00 «Манзара». (6+)
07.25 «Размышления о вере» (6+)
07.30 «Доброе утро!»
08.30, 00.30 Т/с «ДВЕ СЕСТРЫ» (12+)
09.30, 17.30 Т/с «МӘХӘББӘТ ШӘРАБЫ» (12+)
10.30, 01.30 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
11.00 «Кара-каршы» (12+)
12.00, 22.00 Т/с «ЭЗЕЛЬ» (16+)
13.00 Телефильмы «Надежда Дурова, или Штаб-ротмистр Александрова из Елабуги», «Шереметевы. Родина в сердце» и «Казанские мансарды» (12+)
14.00, 18.30 Новости Татарстана (12+)
14.15, 00.00 «Волейбол». Тележурнал (12+)
14.45 «Путь» (12+)
14.55 «Тиззарядка» (0+)
15.00, 21.15 «Хочу мультфильм!» (0+)
15.15, 21.00 «Күчтәнәч» (0+)
15.30 «Мәктәп» (6+)
15.45 «Көлдермеш» (6+)
16.00 «Tat-music» (12+)
16.25 Т/с «ЭНИД БЛАЙТОН: СЕКРЕТНАЯ КНИГА»
17.00, 20.00 Татарстан хәбәрләре (12+)
17.20 «Елмай!» (12+)
19.00 «Мәдәният дөньясында» (12+)
20.30 «Татарлар» (12+)
21.30 Новости Татарстана (0+)
23.00 Т/с «БЛИЗНЕЦЫ» (12+)

ТАТАРСТАН
06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Дороже богатства»
09.20 «Яңа сәлам»
11.30, 14.30, 17.30, 19.40 «Вести-Татарстан»

1 КАНАЛ
05.00, 09.00, 03.00 Новости
05.05 «Доброе утро»
09.15 «Контрольная закупка»
09.45 «Жить здорово!» (12+)
10.55 «Модный приговор»
12.00, 15.00 Новости (с субтитрами)
12.20 «Время обедать!»
13.00 «Доброго здоровьица!» с Геннадием Малаховым (12+)
14.00 Другие новости
14.25 «Понять. Простить» (12+)
15.15 «Хочу знать»
15.50 «Ты не один» (16+)
16.20 «Дешево и сердито» с Дарьей Донцовой
17.00 Т/с «НЕРАВНЫЙ БРАК» (16+)
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.25 «Давай поженимся!» (16+)
19.25 «Пусть говорят» (16+)
20.30 Чемпионат мира по биатлону. Смешанная эстафета. Прямой эфир
21.45 «Время»
22.05 Т/с «ГРАЧ» (16+)
00.00 Ночные новости «Городские пижоны»
00.20 Т/с «КАРТОЧНЫЙ ДОМИК» (16+)

РОССИЯ
05.00 Утро России
09.00 «1000 мелочей». Ток-шоу
09.45 «О самом главном». Ток-шоу
10.30 «КУЛАГИН И ПАРТНЕРЫ». (12+)
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 14.30, 17.30, 19.40 Вести-Татарстан
11.50 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ». (12+)
12.50 «Дело Х. Следствие продолжается». Ток-шоу. (12+)
13.50, 16.45, 04.45 Вести. Дежурная часть
14.50 Т/с «ЕФРОСИНЬЯ. ТАЁЖНАЯ ЛЮБОВЬ»
15.45 Т/с «ТАЙНЫ ИНСТИТУТА БЛАГОРОДНЫХ ДЕВИЦ»
17.50 Т/с «ТОЧКА КИПЕНИЯ» (12+)
20.30 Спокойной ночи, малыши!
20.40 «Прямой эфир». (12+)
21.30 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ-12». (12+)
23.20 «Поединок». Программа Владимира Соловьёва. (12+)
00.55 «Крейсер «Варяг»

НТВ
06.00 Информационный канал «НТВ утром»
08.10 Т/с «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» (16+)
10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня
10.20 «Медицинские тайны» (16+)
10.55 «До суда» (16+)
11.55 Суд присяжных (16+)
13.25 «Суд присяжных. Окончательный вердикт» (16+)
14.35 Т/с «СУПРУГИ» (16+)
15.30, 18.30 Обзор. Чрезвычайное происшествие
16.25 «Прокурорская проверка» (16+)
17.40 «Говорим и показываем». Ток-шоу с Леонидом Закошанским (16+)
19.30 Т/с «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (16+)
21.30 Т/с «ОДИНОКИЙ ВОЛК» (16+)
23.15 Сегодня. Итоги
23.35 Х/ф «БРИГАДА» (18+)
00.40 Т/с «ДЕМОНЫ» (16+)
01.40 «Дачный ответ» (0+)
02.45 Дикий мир (0+)

ЗВЕЗДА
06.00 «Дороже золота» (16+)
06.20, 18.50, 21.20 «Чрезвычайка» (KZN) (16+)
06.30, 14.00, 19.00, 21.30 Новости «Столица» (KZN) (0+)
07.10, 14.15 Т/с «НА ВСЕХ ШИРОТАХ...» (12+)
09.00, 13.00, 16.00, 18.00, 22.00 НОВОСТИ
09.15, 22.30 Т/с «СТАВКА БОЛЬШЕ, ЧЕМ ЖИЗНЬ» (12+)
11.35 Д/с «Освобождение». «Гумбинненская наступательная операция» (12+)
12.05, 19.30 Т/с «ГРУППА «ZETA» (16+)
13.30 «Давай Дружить!» (6+)
16.15 Т/с «ZОННЕНТАУ» (16+)
17.15 Д/с «ВВС. 100 лет и один день». «На борту десант. История военно-транспортной авиации» (12+)
00.40 Х/ф «ГЕНЕРАЛ» (16+)
02.40 Х/ф «Я ТЕБЯ НИКОГДА НЕ ЗАБУДУ» (12+)

КУЛЬТУРА
06.30 «Евроньюс» на русском языке
10.00 «Наблюдатель»
11.15 Х/ф «70 ЛЕТ ПОБЕДЫ ПОД СТАЛИНГРАДОМ. «ЖИЗНЬ И СУДЬБА»
12.35 Д/ф «Сказка его жизни. Никита Долгушин»
13.05 «Абсолютный слух». Альманах по истории музыкальной культуры

13.45 Д/ф «Живая вакцина доктора Чумакова»
14.25 «Полиглот». Французский с нуля за 16 часов! №15
15.10 «Письма из провинции». село Новоалексеевка (Ярославская область). (*)
15.40, 19.30, 00.15 Новости культуры
15.50 Спектакль «ГРАФ НУЛИН». «Комедианты»
17.20 Д/ф «Жизнь как жизнь»
18.00 «В вашем доме». Александр Ворошило
18.45 Важные вещи. «Треуголка Петра»
19.00 Д/с «Великий перемол, или Академическое дело»
19.45 Главная роль
20.05 Черные дыры. Белые пятна. (*)
20.50 Д/с «Запечатленное время». «От Сокольников до парка на метро...»
21.15, 01.55 Д/с «Орбита: необыкновенное путешествие планеты Земля»
22.10 Д/с «Лия Ахеджакова. Обаяние отваги»
22.40 Х/ф «ЖИЗНЬ И СУДЬБА»
00.05 Д/ф «Иван Айвазовский»
00.35 Д/с «Искусство Испании»
01.30 «Тайна скрипичной души»
02.45 Д/ф «Навои»

ЭФИР
05.00 «УТРО» (16+)
08.30, 12.30 «Новости 24» (16+)
09.00 «Нам и не снилось»: «Замужем за мафией» (16+)
